КИРӘКЛЕ ЯРДӘМ

Авылда эш башлаучыларга грантлар яңартыла

> 5

ЫШАНСАҢ ЫШАН

Женнәрдән ничек сакланырга?

> 16

АЛЬФРЕД ЯКШИМБЕТОВ:

«Минемчә, Салават – дәрес кеше. Дөньяга аек акыл белән карый торган кеше»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 142 (29109) | Җомга | 29 сентябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

СОҢГЫ МОГИКАННАР

ИНДЕ ҖИДЕ ЕЛ БУ АВЫЛДА НИБАРЫ ӨЧ КЕШЕ ЯШИ

Борчаклы Язда борчак та үсми, язлар да башка хәзер. Кайчандыр шаулап торган авылда – тынлык. Шушы авылда 65 ел гомер кичерүче Жуковларның этләре өргән тавыш кына ниндидер бер җанлылык өсти. Ике йортка – өч кеше. Картларның кыштыр-кыштыр гына үз көенә яшәп ятулары. Гомер көзләрендә барысы да сагынырга гына калган.

> 7

Ишетми калмагыз

Россия Хөкүмәте әйбәт, «сәламәт» бюджет төзегән. Финанс министры Антон Силуанов әйтүенчә, бюджет әле тагын үсәчәк. Иң мөһиме – ниндидер өлкәләргә акчаны «кисү» күздә тотылмый.
Министр сүзләренә караганда, киләсе ел бюджетына 36,6 триллион сум салынган. Шул ук вакытта бюджетта, юнәлешен үзгәртеп, кирәклерәк максатка җибәреп булган 500 млрд сум күздә тотылган.

Казан эшмәкәрләр һәм үз эшен яңа гына ачучылар өчен иң уңайлы шәһәрләр рейтингында 7 нче баскычта урнашкан. Исемлек Forbes журналы сайтында дөнья күргән. Аны төзүчеләр мәгълүматлары буенча, Татарстан башкаласы икътисадында кече һәм урта бизнесның өлеше 42,2% тәшкил итә. Шул ук вакытта республиканың иң зур 10 сәнәгать һәм энергетика компаниясе арасыннан дүртесе Казанда урнашкан. Болар – «Оргсинтез Казан», «Татэнерго», ТГК-16 һәм «Нәфис Косметикс».
Краснодар бизнес алып бару өчен уңайлы шәһәрләр унлыгында беренче урынга чыккан. Южно-Сахалинск – икенче, Төмән – өченче. Рейтингка Россиянең 30 шәһәре кертелгән.

Татарстан суд приставлары ел башыннан бирле ЮХИДИ штрафларын түләмәүче 832 кешенең автомобиленә арест салган. Приставлар әйтүенчә, шәхси транспорттан мәхрүм калу куркынычы ваемсыз йөртүчеләрне бик тиз акылга утыртырга ярдәм итә.
Суд приставлары идарәсе, мондый хәлдә калмас өчен, бурычны вакытында идарәнең рәсми сайтында яки Дәүләт хезмәтләре порталындагы шәхси кабинет аша түләргә киңәш итә.

Октябрь башында Татарстанда җылы һәм яңгырлы көннәр көтелә.
Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, шимбә-якшәмбе – 30 сентябрь һәм 1 октябрьдә республика антициклон йогынтысында кала. Явым-төшем ихтималы аз.
30 сентябрьдә көндез +15...+20 градус. Төнлә +4...+9.
1 октябрьдә көндез термометрның терекөмеш баганасы +18...+23 градуска кадәр күтәреләчәк. Төнлә +2...+7, ә көнбатыш районнарда +11 градус булырга мөмкин.
Синоптикларның фаразларына караганда, дүшәмбе һәм сишәмбе – 2–3 октябрьдә урыны белән яңгырлар көтелә. 2 октябрьдә көндез һава температурасы +16...+21 градус, 3 октябрьдә +14...+19 градус чикләрендә тирбәләчәк.
Сүз уңаеннан, октябрьдә айлык уртача температураның нормадан югарырак булуы көтелә. Бу ай өчен норма +4,9 градус тәшкил итә.

Районнарда ни хәлләр?

Кукмара

Үрәсбаш авылында яшәүче Родион Иванов хуҗалыгында сыер, бозау, кәҗә, понидан тыш, бер елдан артык асыл болан (марал) да яшәгән. «Узган елның 24 июнендә хуҗалык бригадиры комбайн суккычына эләккән ярым үле хәлдәге җан иясе алып кайтты. Күптән түгел генә туган әлеге кыргый урман хайванының алгы аягы сынган, арткысы сөягеннән чыккан, бот өлешендә тишек тә бар иде. Тиешле оешмалар белән сөйләшеп, мин моны өйгә алып кайттым», – дип сөйли ул. Бер ел буе ул болан баласын тәрбияләп, ниһаять, аякка бастыра. Бүген ул иректә. «Саба районының урман массивында махсус әйләндереп алынган зур гына кишәрлек бар. Анда аңа күпкә уңайлы булыр дип уйлыйм», – ди Родион Иванов.
(«Хезмәт даны»)

Апас

Морзалар авылында яшәүче Илфир Сәлахов махсус операция зонасындагы якташларына җибәрү өчен, шәхси «УАЗ» автомобилен ремонтлаган. Тиздән аны хәрбиләр кабул итеп алачак. «Махсус хәрби операция зонасындагы егетләребез, гомерләрен куркыныч астына куеп, Ватанны саклый. Без аларга ярдәм итү өчен кулдан килгәннең барысын да эшләргә тиеш. Алга таба да аларга ярдәм итәчәкмен», – ди Илфир Сәлахов. Апас районы башлыгы Айрат Җиһаншин хәрбиләргә ярдәм күрсәткәне өчен аңа рәхмәт белдерде.
(«Татар-информ»)

Мөслим

Мөслим мөхтәсибәтендә күркәм вакыйга булды – район үзәгендә дүртенче мәчет ачылды. Аны «Разалия» мәчете дип атадылар. Мәчет Мөслим авылы үзәгендә урнашкан. Бина 2021 елның сентябрь аенда төзелә башлап, ике ел эчендә сафка басты. Бер катлы дин йортында ир-атлар һәм хатын-кызлар заллары һәм тәһарәтханәләр бар. Мәчеттә берьюлы 45 ир-ат һәм 10 хатын-кыз намаз укый ала. Мәчетнең имамы итеп Ислам хәзрәт Шәфыйков сайланды. Хәзерге вакытта районда 37 мәчет эшли.
(dumrt.ru)

Мамадыш

21–24 сентябрьдә Мамадышта «Havaфест» һава шарлары фестивале узды. Чарада Россиянең төрле почмакларыннан килгән аэронавтлар катнашты. Бу матур күренеш шаһитлары арасында шәһәр һәм район халкы гына түгел, республиканың башка районнарыннан килгән кунаклар да бар иде. «Фестиваль бик ошады! Без монда Чаллыдан килдек. Бик кызыклы чара», – диде Фәридә һәм Мансур Сәйфуллиннар. Теләгән һәркем, һава шарына утырып, 1000 метр биеклеккә кадәр күтәрелә алды.
(tatarstan24.tv)

ЯКЫН ИТЕП

tatarstan.ru

Төрекмәнстан бәйсезлегенең 32 еллыгына багышланган чараларда Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Бу ил җитәкчелеге чакыруы буенча сәфәр кылган Татарстан Рәисе Төрекмәнстан Президенты Сердар Бердымөхәммәдов һәм Халк Мәсләхәте Рәисе Гурбангулы Бердымөхәммәдов белән очрашты.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, бүген дөньядагы катлаулы шартларда Россия белән Төрекмәнстан арасындагы хезмәттәшлек аеруча әһәмиятле. Һәм Татарстан бу элемтәләрне ныгытуга бар көчен куярга әзер. «Төрекмәнстан Татарстан өчен һәрвакыт стратегик партнер булды», – диде Рөстәм Миңнеханов Аркадаг каласында Гурбангулы Бердымөхәммәдов белән очрашуда. Аның сүзләренә караганда, икътисадый хезмәттәшлеккә яңа көч-куәт бирергә кирәк. Автомобиль төзелеше, суднолар төзү, газ транспортлау, энергетика, нефть чыгару кебек тармакларда бергәләп эшләү өчен мөмкинлекләр бар.

Татарстан белән Төрекмәнстан арасындагы элемтәләр

- Бу илдә «Татнефть», КАМАЗ, «КЭР-холдинг» компанияләренең филиаллары эшли.
- Сердар Бердымөхәммәдов Президент вазыйфасына сайлангач, Рөстәм Миңнеханов аның белән Россиядәге рәсми затлар арасыннан беренчеләрдән булып очрашты. Быел алар 4 мәртәбә күреште.
- Халк Мәсләхәте Рәисе Гурбангулы Бердымөхәммәдов узган ел Казанга килде.
- Казанда Төрекмәнстанның генераль консуллыгы эшли.
- Татарстанда Төрекмәнстаннан килгән 6 меңнән артык студент белем ала.
- Төрекмәнстанда 15 мең чамасы татар яши.
- Татарстан Рәисе йортында 2021 елда Гурбангулы Бердымөхәммәдов бүләк иткән Алабай токымлы эт – Акдус яши.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Пермьдә Идел буе федераль округы Советы утырышында катнашты. Россия Президентының округтагы тулы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров рәислегендә узган чарада яшьләр сәясәте турында сөйләштеләр. Утырышта Игорь Комаров Рөстәм Миңнехановка Россия Президентының Рәхмәт хатын тапшырды. Татарстан Рәисе илнең төзелеш тармагы һәм торак-коммуналь хуҗалык үсеше стратегиясен тормышка ашыруга керткән өлеше өчен бүләкләнде.

ХОКУК ҺӘМ ХӘЯТ

Мәктәпләргә – Конституция дәресе, халыкка – күзгә-күз карап аралашу. Казанда халыкара юридик форум башланды. Аның эшчәнлегендә хакимият вәкилләре, юристлар, экспертлар берләшмәсе катнаша. Көн кадагында – борчыган сораулар, ниятләгән эшләр.

Татарстан җитәкчелеге исеменнән форум кунакларын Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин сәламләде.

– Татарстан Республикасы һәм аның башкаласы юридик белем бирү һәм фән буенча дан казанган үзәкләрнең берсе булып тора. Казан юридик мәктәбе Россиядә һәрвакыт югары бәяләнде, әмма аның күренекле укучылары илебездә генә түгел, чит илләрдә дә билгеле, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Юридик берләшмәнең бурычы – һәрвакыт закон, кеше, дәүләт мәнфәгатьләрен яклау, хокукый аңны арттыру.

Кеше белән эшләү, диләктән. Татарстан парламенты җитәкчесе әйтүенчә, цифрлаштыру өлкәсендә алга китсәк тә, хокукый сорауларга җавап табуда халыктан ерагаерга, барысын да санлы технологияләргә генә аударып калдырырга ярамый. Форум кысасында да халыкны борчыган сорауларга игътибар итәргә тәкъдим итте ул.

– Безгә халыктан ерагаерга түгел, киресенчә, аларга күбрәк мөмкинлек бирергә кирәк, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Форум кысасында илнең Төп законына багышланган фикер алышу да узды. Билгеле булганча, алда Конституциянең 30 еллыгы көтелә. Форумда катнашучылар 2020 елда Конституциягә кертелгән үзгәрешләр хакында сөйләште.

– Татарстанда яшәүчеләр Төп законга үзгәрешләр кертүгә тавыш бирде, төзәтмәләрне хуплады. Бу безнең халыкларның бердәмлеген, дуслыкны ныгытырга мөмкинлек бирде, – диде бу җәһәттән Фәрит Мөхәммәтшин.

Конституция дигәннән, Россия Дәүләт Думасының Дәүләт төзелеше һәм законнар чыгару комитеты рәисе Павел Крашенинников Казан мәктәпләрендә илнең Төп законы буенча ачык дәресләр уздырырга тәкъдим итте.

– Юбилей гына түгел, 30 еллык көтелә. Ачык дәресләр уздыру практикасын кулланырга һәм аны традиция итәргә кирәк, – диде Павел Крашенинников.

Константин ЧУЙЧЕНКО, Россия юстиция министры:
– Бүген без аерым илләрнең сәяси амбицияләренә ярарга теләп, халыкара хокук институтларының акрынлап юкка чыгуын, халыкара килешүләр нигезләмәләренең игътибарсыз калуын, кеше хокуклары һәм ирекләренең шик астына куелуын, суверен тигезлек һәм дәүләтләрнең эчке эшләренә тыкшынуны күзәтә алабыз. Җәмгыять өчен чит идеяләр һәм кыйммәтләр системасының үсүе көннән-көн ачыграк күренә. Әмма бу шартларда Россия традицион рухи-әхлакый принципларга, шул исәптән хокукка тугры калды.

РУХ һӘМ ТӘН НЫКЛЫГЫ

Татарстан мөселманнары Мәүлид бәйрәмен билгеләп үтте. Изге Болгар җирендә узган бәйрәмдә Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев катнашты. Догалар кылынды, теләкләр әйтелде, рух ныклыгы белән тән саулыгы турында сөйләштеләр: Болгар ислам академиясендә спорт мәйданчыгы ачылды, шунда ук беренче уен да узды.

Татарстанда 2014 елдан бирле Мәүлид ән-Нәби уңаеннан төп бәйрәм чаралары Болгардагы Ак мәчеттә үткәрелә. Намаз залында Коръән сүрәләре, гарәп һәм татар телләрендә дини көйләр яңгырый.... Быел исә Изге Болгар җирендә тагын бер вакыйга булды – Ислам академиясе янында спорт мәйданчыгы ачылды. 765 кв. метрлы әлеге спорт объекты Ислам мәдәнияте, фән һәм мәгарифкә ярдәм фонды белән берлектә төзелгән.

– Татарстанда Болгар академиясен булдыру Россия өчен тарихи вакыйга булды. Бүген әлеге уку йорты булачак дин белгечләренә белем һәм һәрьяклап үсеш өчен мөмкинлекләр бирә. Яңа ачылган спорт мәйданчыгы да студентлар өчен өстәмә уңай шартлар тудыра, – диде Минтимер Шәймиев, кунакларны бәйрәм белән тәбрикләп һәм уен башланыр алдыннан тупка беренче булып үзе типте.

Болгар ислам академиясе – Россия Президенты Владимир Путин тарафыннан хупланган федераль проект.

Тантанада Татарстан Рәисе Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Ислам мәдәнияте, фән һәм мәгарифкә ярдәм фонды директоры киңәшчесе Алексей Петров һәм башкалар катнашты.

– Укучылар рух һәм белем белән генә түгел, физик яктан да көчле булырга тиеш. Бәйрәм көнне шундый мәйданчык ачылу – куанычлы вакыйга, – диде Камил хәзрәт Сәмигуллин.

Аның сүзләрен Болгар Ислам академиясе ректоры Фәрхәт Хөснетдинов куәтләде.

– Академиябез янында күпфункцияле спорт мәйданчыгын ачу тантанасы да зур бәйрәмгә туры килде. Башка уку йортлары кебек үк, безнең академия дә студентларга белем бирү белән генә чикләнми, аларга төрле яклап үсәргә ярдәм итә, – диде ул.

Тантаналы ачылыштан соң Минтимер Шәймиев академия студентлары белән очрашып сөйләште.

– Болгар Ислам академиясен дә, аның студентларын да матур киләчәк көтә. Монда белем алган дин белгечләре киләчәктә ислам үсешенә үз өлешләрен кертәчәк, – диде ул. – Без төзегән матур бинаның тирән эчтәлекле булуы куанычлы. Без алга таба да республикада ислам мәгарифенә ярдәм итәчәкбез, шул исәптән уку шартларын да яхшыртачакбыз. Якын киләчәктә академия территориясен төзекләндерүгә керешергә кирәк. Мәүлид бәйрәмендә яңгыраган ниятләр бик җаваплы, без аларны үз көчебез һәм Аллаһы Тәгалә ярдәме белән тормышка ашыра алырбыз дип өметләнәм.

«Татар-информ»

Ахырда ул Шәймиевләр гаиләсе һәм барлык туганнары исеменнән Болгар ислам академиясенә танылган ислам дине белгечләренең 60 томлык китапларын бүләк итте. Бәйрәм чараларында катнашучылар Ак мәчеттә өйлә намазын да укыды. Шуннан Минтимер Шәймиев I төбәкара «Болгар легендасы» симпозиумында катнашучы рәссамнарның эшләре белән танышты. Болгардагы бәйрәм концерт белән тәгәлләнде.

САН

Татарстанда **2112** гыйбадәт йорты бар. Аларның якынча **90** проценты ислам һәм христиан (православие) диннәренә карый.
Хәзерге вакытта республикада **32** мәчет, **40** чиркәү (**39**ы реставрацияләнә) төзелә.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың сәнәгать потенциалын ныгытуга һәм үстерүгә зур өлеш кертүләре, күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Союзхимпромпроект» проект институты хезмәткәрләре: генплан һәм тикшеренүләр бүлеге башлыгы **Җиһаншин** Марат Дамил улы, автоматлаштыру бүлеге башлыгы **Исхаков** Илнур Ленар улы, директор **Кочнев** Павел Владимирович, баш бухгалтер **Култашева** Елена Алексеевна, 6 номерлы монтаж-технология бүлеге башлыгы **Рыбаков** Виталий Владимирович **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Азнакай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең ультратавыш ярдәмендә диагноз кую кабинеты мөдире – ультратавыш ярдәмендә диагноз кую табибы **Бакиров** Әсгать Госман улына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор Е.В. Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең кабул итү бүлекчәсе мөдире – табиб-офтальмологы **Бушманова** Татьяна Марат кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор Е.В. Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе табиб-офтальмологы **Гыйматдинов** Рамил Равил улына, «Лениногорск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының поликлиника ярдәме буенча урынбасары **Зарипова** Розалия Әбүзәр кызына, «Азнакай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең балалар поликлиникасы шәһәр участок педиатрия бүлекчәсе участок табиб-педиатры **Морадымова** Луиза Инзил кызына, Казан шәһәренең «М.Н. Садыйков исемендәге 7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе табиб-неврологы, үзәк нерв системасы функцияләре бозылган авыруларны медицина ягыннан тернәкләндерү бүлекчәсе мөдире **Хөсәенова** Эльмира Рөстәм кызына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Азнакай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе ашыгыч медицина ярдәме бүлекчәсенең ашыгыч медицина ярдәме фельдшеры **Әхмәтова** Зөлфия Илгизәр кызына, Казан шәһәренең «10 номерлы шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең процедура кабинеты өлкән шәфкать туташы **Закирова** Фирая Нурьяздан кызына, «Буа үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Килдураз фельдшерлык-акушерлык пункты мөдире – фельдшеры **Исмәгыйлева** Флёра Тәлгать кызына **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Союзхимпромпроект» проект институты архитектура-төзелеш бүлеге төркеме җитәкчесе **Коваленко** Светлана Григорьевнага **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Без булдырабыз

«Без булдырабыз!» – дигән шигарь бар. Хәзер аны бераз ирония белән кабатларга күнегеп баралар. Бик күп өлкәләрдә алга китеш тукталып, тискәре нәтиҗәләр хасил булгач, шулай итәсе килеп торадыр инде. Бүтәннәрнең уңышсызлыгыннан көлүдән дә җайлырак, рәхәтрәк халәт юк. Нәрсәдер эшләргә тырышып, хаталанган адәм янында кыл да кыймылдатмый торган ата ялкаулар да үзен эшлекле итеп тоя. Һәм изге максатлар белән ялгышкан теге адәмнән көләргә маташалар:

– Кит инде, шуны да эшли алмагач…

Андый ялкаулар, гадәттә, күп була һәм бер мизгелдә аларның сүзе халык сүзе кебегрәк тә яңгырап китә. Ахмаклар да күп. Намуссызлар да. Көнчеләр дә. Бу халыкның әллә кемнәре бар. Бер үк кеше дә кайчагында ахмак та, намуссыз да, көнчел дә булып алырга, әллә нинди сурәтләргә кереп чыгарга мөмкин. Кайчагында кеше башкалар йогынтысына да бирелә, мода агымына да иярә, бүтән сәбәпләр дә табыла. Шуңа күрә, кеше ниндидер ахмаклык эшли икән, бу әле аның гына ахмаклыгын аңлатмый. Аның ахмаклыгын гына да аңлатмый.

Ничек кенә булмасын, миңа ошый бу шигарь. Без булдырабыз. Яктылыкка, җиңүгә юнәлтелгән ул. «Мин булдырам!» – дисәң дә алай ук яңгырамый, мактануга да каера, ялгызлыкны да аңлаткан кебек. Ә без булдырабыз – бөтенләй икенче. Хәтта берүзең генә ниндидер эшкә тотынсаң да: «Без булдырабыз!» – дип әйткәч, артыңда кемдер торган шикелле тоела. Ялгызың гына түгелсең, һәр минутта килеп кушылырдай дусларың, ярдәмчеләрең бардыр сыман.

Монысын көнкүрештәге һәм иҗаттагы тәҗрибәләр буенча әйтәм. Кулдан килмәс кебек тоелган эшләрне дә шул шигарь белән җиңеп чыкканым бар. Ул үзеңә ышанычны арттыра, бөтен сәләтеңне, көчеңне тупларга мәҗбүр итә.

Булдыра алмаган вакытлар да очрый. Кешенең үзеннән генә тормаган нәрсәләр дә күп бит инде. Кеше генә түгел, ә тоташ халыкларның, дәүләтләрнең кулыннан килмәгән нәрсәләр дә бар. Менә быел җәй көне яңгыр көттек. Аны: «Без булдырабыз!» – дип кенә яудырып булмый бит инде. Ил өстендәге вазгыятьне дә алай дип кенә үзгәртеп булмый. Бер селтәнүдә алай килеп чыкмый. Ваграк мәсьәләләрдә дә шулай булырга мөмкин. Бер шигарь дә тылсымчы таягы түгел, хәтта алай булган хәлдә дә, бер тылсымнан көчлерәк бүтән тылсым булырга мөмкин. Бер генә без булдырмыйбыз бит, булдырырга тырышучы бүтән көчләр дә бар. Аннан соң, бер халәт тә бертуктаусыз түгел. Берәүлексез уңыш та, җиңү дә, бәхет тә булмый. Шуңа күрә, булдыра алган кадәренә канәгать калып, булдыра алмаганын булдырырга тырышып яшәргә кирәк. Андый чакта мин үземне уены-чыны белән болай юатам:

Без булдырабыз. Булдырсак,
Барысын да уздырабыз.
Ә булдыра алмаганда,
Булганын туздырабыз…

Нәрсәгәдер ирешә алмау гел генә синең көчсезлегеңне, беткәнбаш уңышсыз икәнеңне аңлатмый әле. Кайбер нәрсәләрнең вакыты җитмәгән булырга да мөмкин. Тугыз хатынны авырга уздырсаң да, бер айдан бала тумый, диләр бит. Бөтен нәрсә артыннан да чабып йөри алмыйсың, кайберләренең үзе килгәнен көтәргә кирәк. Каршыларга әзер торырга.

Максатыңа ирешү өчен мөмкинлекләр тудырылу гына җитми. Беренчедән, максатың булу кирәк. Һәм шул максатыңа ирешә алачагыңа ышану. «Без булдырабыз!» – дигән ышаныч.

Әйтеп кенә бактым

Безнең күңелләр

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Беркөнне эшкә таксида бардым. Машинага кереп утыруга, иминлек каешын эләктердем. Шофер егет миңа сәерсенеп карап куйды. «Нәрсә, үлемнән куркасызмы?» – ди.

«Кем курыкмый инде», – дим. «Мин», – ди бу. Үз чиратымда, аңа мин сәерсенеп карап куйдым. Сүзгә бик юмарт булып чыкты таксист егет. Махсус хәрби операциядә катнашкан икән, яраланып, госпитальгә эләккән. Дәваланып чыккач, тәмам аякка басар өчен ял биргәннәр. Үзе әйтмешли, аңа ял килешми икән, шуңа күрә вакытлыча таксист булып йөри. Тик тыныч тормышны ошатмый бу, тизрәк тегендә китәргә тели. «Одна скукота, как вы тут живете?» – дип җибәрә. Күңелдән генә: «Әһә, моның психикасы бозылган», – дип куйдым. Тыныч тормыштан кем туйган инде?!

Таксист Андрей исемле икән. Мин аның сөйләгәннәрен татарча язам инде. «Үлемнән җүләр генә курыкмый. Тик мин үлемне психологически җиңәргә өйрәндем. Ничек итеп, дисезме? Алдыма максат куеп. Мин ни өчен бу операциядә катнашуымны беләм. Үлә-нитә калсам, дуслар, туганнарның минем турыда ни сөйләячәген беләм. Андрей куркак булган, дип берәү дә әйтмәячәк. Әйе, миңа кешегә атарга да, утерергә дә туры килде. Ну без бит үзебезне кешегә санамаганнарга каршы сугышабыз». Андрей үзе сөйли, үзе миңа карап-карап ала, йөземдә аның әйткәннәрен хуплау галәмәтләре күрмәкче була, ахрысы. Ә мин хисләрне тышка чыгармаска тырышам. Андрей шулай да ни уйлаганымны сизенә: «Сугыш кешене үзгәртми калмый инде ул», – ди. Аңа тыныч тормышның кызыгы беткән. Тизрәк махсус операциягә җибәрүләрен сорап, хәрби комиссариатка да мөрәҗәгать иткән. «Без гарип кешене җибәрә алмыйбыз, башта терелеп бет әле», – дигәннәр. Мин Андрейдан Ватанны ярату, Ватанның иминлеген саклау турында матур сүзләр көтмәдем. Заманында кайберәүләрнең, сугышка бармас өчен, үз-үзләрен гарипләндерүләрен искә төшердем. «Сугыш вакытында йә кулларына, йә аякларына атучылар булган бит», – дидем. Андрейның минем сүзләргә артык исе китмәде. «Андыйлар һәрвакыт табылачак», – диде. Аптырагач: «А как чувство патриотизма?» – дигән булам. Андрейның җавабы бик гади иде. «Мине ни өчен монда бәргәләнә, үзенә урын таба алмый, дип уйлыйсың? Минем сугышка ыргылуым адреналин җитмәүдән яки психикам бозылудан түгел. Тегендә минем дусларым, хезмәттәшләрем калды. Как они там без меня? Очень хочу помочь, но не могу, вот это меня бесит», – ди.

Нишләмәк кирәк, тормыш еш кына һәр кешене Ватанны саклау һөнәрен үзләштерергә мәҗбүр итә инде. Бөтен кеше, мәсәлән, табиб була алмый, ә Ватан сакчысы була ала. Чөнки туган илне ярату хисе һәркем күңелендә бар. Кем әйткәнне инде хәтерләмим, әмма «Ватанны ярату – кешеләрне ярату ул», – дигән сүзләре күңелдә калган. Ә бу хис кемдә юк?

Гаҗәп кешеләр инде без. Берәү йорт салырга кредит алган булган. Махсус хәрби операциядә контракт төзеп катнашу турында сүз чыккач, моның хатыны: «Берничә айга булса да барып кайтмыйсыңмы соң, аена 200 мең сумнан артык акча бирәчәкләр икән, кредит түләр идек», – дигән. Ир берсүзсез риза булган. Әмма медицина комиссиясе моны хәрби хезмәткә яраксыз дип тапкан. Шуннан ир белән хатын нишләгәннәр, дисезме? Берсеннән-берсе уздырып, табибларны сүгә башлаганнар. Әлбәттә, кредит түләү мөмкинлеге юкка чыгу да ачуларын китергән. Әмма акча икенче планга күчкән. Хатыны иренең армиягә яраксыз икәнлегенә үрсәләнсә, ире: «Башкалардан кай җирем ким?» – дип хурлана икән.

Әле без үсмер чакта да армиягә яраксыз дип табылу егет кеше өчен оят, түбәнлек иде. Димәк, мондый хисләр дә күңелләрдә тирән тамыр җибәргән.

БЕНЗИН БЕЛӘН БИЛ АЛЫШУ

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Укучылар, бәлки, хәтерли торганнардыр: гыйнвар аенда без мотор ягулыгы темасына махсус ике язма багышладык. Беренчесендә мондый сүзләр яздык: «Илдә мотор ягулыгының зур дефициты пәйда булырга мөмкин. Сум түбәнгә тәгәрәр, бәяләр күтәрелер, бюджет кысыр калыр. Алардан да бигрәк бензин кытлыгы үзәккә үтәчәк». Күрәсез, без икътисадның бүгенгесен ничек төгәл фаразлаганбыз. Әлегә бензин кытлыгы ук юк югын, әмма бәяләр сизелерлек күтәрелде һәм, начар фараз ясаган өчен гафу итегез инде, күтәреләчәк. Икенче язмада да фаразны уңайга үзгәртмәгәнбез: «...бәяләр тотрыклы калган хәлдә, бензинга кытлык туу куркынычы зур. Ягулык дефициты булмасын өчен, бәяләрне кискен күтәрү ихтыяҗы туачак». Элгәреге язмада: «Бу проблемага каршы Мәскәүдә берәр чара бардырмы?» – дип тә сорау куйганбыз.

Без – дилетантлар, билгеле, әмма без ясаган икътисадый фаразлар гадәттә тормышка аша. Әлегә кадәр ашмаган булса, борчылмагыз, ашачак. Чөнки бу юлларның авторы «арифметика» дигән элементар фәнне башлангычта укыганда үзләштерде дә онытмады. Безнең фаразларны тагын бер тапкыр игътибар белән укыгыз әле: мотор ягулыгы кытлыгына каршы хөкүмәт чара таба алмаячак, без шуны алдан әйткәнбез. Вазгыятьне карап барган укучы бәхәсләшер: яңа гына хөкүмәт нефть продуктларын читкә сатуны тыйды, шулай булгач, бәяләр төшәчәк, дияр. Килешәбез: нәрсәнедер читкә сатуны туктатсаң, эчке базарда ул арта, бәяләрне төшерүдән башка чара калмый. Әмма бу кагыйдә бүгенге вазгыятьтә бензин һәм дизель ягулыгына кагылмый. Киресенчә, тыю дефицитка һәм бәяләр күтәрелүенә генә китерәчәк. Бу фикерне дәлилләү өчен, кулда фактлар шулкадәр күп: автор кыска язмада аларны ничек сыйдырырга дип борчыла.

Рәсми чыганаклардан файдаланып, ни өчен дигән сорауга җавап бирик. Тыю кергәнгә берничә көн узды инде. Беренче көннәрдә ягулыкның биржа бәяләре кискен түбәнәйде. Котировкалар 20 процентка кадәр төште. Ләкин... шуннан соң да солярканың күпләп сату бәясе алдагы елларның иң югары бәясеннән югарырак калды, бензин 2021 елгы рекордтан чүт кенә түбәнәйде. Әмма бу – вакытлы күренеш. «Российская газета» хәбәр итә: «При этом 26 сентября падение цен остановилось, они опять пошли вверх», – ди. 27 сентябрь иртәсендә минем телефон да мотор ягулыгына биржа бәяләре янә күтәрелә башлавын әйтте. Ягулыкның ваклап сату бәяләре төшмәде, хәтта күтәрелүләрен дәвам итте. «Оперативных новостей о снижении цен на заправках не было. А вот сообщения об отсутствии топлива на некоторых АЗС в разных регионах были», – дип хәбәр итә бу хакта федераль хөкүмәт газетасы. Мәскәү кабул иткән карарның тәэсире бер атнага бармады. Без фаразлыйбыз: экспортны тыю турындагы карарны кичекмәстән юкка чыгармасалар, бензин дефициты башланачак. Игътибар итегез: әлегә кадәр солярка дефицита иде һәм аңа бәяләр котырып күтәрелде. Хәзер ике ягулыкның уртак дуэты көтелә. Аек акылга сыймый бу диярсез инде. Ничек кенә сыя әле. Сүзне Дәүләт Думасының Энергетика комитеты башлыгы Завальныйга бирик. «Россиядә бензинга түбән бәяләрне тоту мөмкин түгел», – ди ул. Һәм дөрес әйтә.

Ни өчен шулай? Саннар белән арифметик исәпләүләрне китереп тормыйбыз, сүзгә генә ышанугызны сорыйбыз. Мотор ягулыгы кытлыгының һәм аңа бәяләрнең күтәрелүенең сәбәпләрен ачык матбугат кырындагы рәсми аңлатуларның берсе дә дөрес түгел исә өлешчә генә дөрес. Өстән-өстән генә ул сәбәпләрне санап чыгыйк: нефть эшкәртү заводлары ремонтка туктады, махсус хәрби операциядә дизель ягулыгы күп тотыла, нефтьчеләр бәяне күтәрергә

«Татар-информ»

теләп, дефицитны махсус оештыра, ягулык демпферы киметелде. Соңгы сәбәп бәя күтәрелүдә мөһим роль уйный. Хөкүмәт элек тышкы базарда нефтькә бәяләр үскәндә, ягулыкны эчке базарда сатучыларның югалтуларын акча түләп кире кайтарды. Бензинны читкә сатсаң да, ил эчендә кулланса да, оттырмадың. Казнаның хәле бик үк шәп түгел, махсус хәрби операциягә бик күп акча китә, шуңа күрә сентябрьдән демпферны ике тапкыр киметтеләр. Әмма ягулык кытлыгы һәм бәяләр күтәрелү җәйдән үк килә инде, шуңа күрә хөкүмәтнең түләүләрен кире кайтарып була, кытлыктан котылып булмый. Калган сәбәпләр тәнкыйтьне күтәрә алмый, чөнки ремонт ел да була, мондый хәл күзәтелмәде. Хәрби хәрәкәтләр дә 2022 елда ук масштаблы барды, кытлык булмады.

Асыл сәбәп башкада. Европалылар 5 февральдән Россиянең нефть продуктларына эмбарго кертте. Хәлләр шуннан соң кискенләште. Товарны Азия һәм Африка базарларына озатырга туры килде. Әмма ул базарларда безнең ягулыкка ихтыяҗ алай зур түгел. Сатсаң, бик арзанга сатасың, сатмасаң, тик утырасың. Аеруча мазутны урнаштыру кыенлашты. Әле бу атнада гына Пакьстан бездән нефть сатып алырга ризалык белдерде, әмма: а) түшәм бәядән түбәнгә; ә) нефтьне эшкәрткәннән соң, мазутны кире кайтарып бирү шарты белән. Бездә резервуарлар болай да мазут белән тулы. Шуны куярга урын булмау сәбәпле, заводлар эшне акрынайта. Кытлыкны шул тудыра. Әле ярый гарәпләр бераз мазут сатып ала.

Дизель ягулыгын һәм бензинны читкә сатуны тыеп, хөкүмәт проблемага проблема өстәде. Эчке базарда солярка артык була башлады. Заводлар инде хәзер мазутны гына түгел, дизель ягулыгын куярга урын булмаганлыктан ябылачак. Бензин бетәчәк. Кабатлыйм: бензин бетәчәк! Хөкүмәтнең тыю турындагы карары ярты-йортылы булу гына коткара безне. Ягулыкны Таможня союзы илләренә сату чикләнми. Нефтьчеләр бу тишекне файдаланып, читкә Казахстан, Әрмәнстан, Беларусь аша чимал озата башлар. Алсыннар өчен, күпкә арзангарак сатарга туры килер. Мазут проблемасы калыр барыбер. Ул безгә озак вакытлы кризис вәгъдә итә. Мазутны тирәнтен эшкәртү заводлары тәэмичә, кризистан чыгып булмый. Аның өчен технологияләр һәм җиһазлар кирәк, алар – Көнбатышта.

Россиянең авыл хуҗалыгы министры Дмитрий Патрушев вазгыятьне «катастрофа» дип бәяләде. Ул үз каланчасыннан торып карый, чөнки белгеч түгел, шуңа күрә һәлакәттән ягулыкны читкә сатуны тыеп котылмакчы. Вазгыятьтән чыгу юлы бар барын, әмма аны әйтергә ярамый.

Зөһрә
САДЫЙКОВА

АРТЫГЫ БУЛМАС

АВЫЛ ХАЛКЫ НИНДИ ГРАНТЛАРГА ӨМЕТЛӘНӘ АЛА?

«Татар-информ»

Иш янына куш өстәлсә, тагын да күңеллерәк. Төрле программаларда катнашып, ярдәм ала алган авыл халкы әнә шулай ди. Моңа кадәр уңышлы эшләп килгән программаларга быел яңалары да өстәлде. Әйтик, Татарстанда эшләрен яңа гына башлаган кооперативларга грантлар бирүне яңарттылар, ат тотучыларга ярдәм чараларын киңәйттеләр һәм чеби алучыларга субсидияләрне кайтардылар. Шәхси хуҗалыклар һәм үз эшен булдырырга алынган яшь фермерлар тагын нинди ярдәмгә өметләнә ала?

Шәхси хуҗалыкларга ярдәм

Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Рөстәм Гайнуллов әйтүенчә, Татарстан казнасыннан иң зур ярдәм шәхси хуҗалыкларга бирелә. Чөнки нәкъ менә алар авыл хуҗалыгы продукциясенең 32 процентыннан артыграгын җитештерә.

Беренчедән, **сөтчелек тармагын үстерү өчен халыкка мини-фермалар төзү**гә субсидияләр бирелә. Абзар салыр өчен, сигез сыер асраучылар – 600 мең сум, биш сыер тотучылар 300 мең сум ярдәмгә өметләнә ала. Субсидия алуның төп шарты – биш ел дәвамында терлекләрнең баш саннарын киметмәү.

Икенчедән, **сатыла торган токымлы терлек алу өчен субсидия**. Бәйгедә җиңүчеләргә нәселле таналар сатып алуга – 60, бер тапкыр бозаулаган яшь сыерлар сатып алуга 70 мең сум күләмендә акча бирелә.

Өченчедән, **сыер асраучыларга ел саен 2–4 мең сум күләмендә акча** бирелә. Әлеге ярдәм – халык арасында иң популярыдыр, ахры. Абзарында сыеры булган һәр кеше бу ярдәме алырга тырыша. Быел да аны 35 меңнән артык кеше алган. Әлеге максатларга 350 млн сум акча бүлеп бирелгән.

Дүртенче ярдәм **ат асраучыларга** кагыла. 3 яшьтән зуррак һәр атка 5 мең сум күләмендә субсидия бирелә. Яңалык буларак, быелдан бер хуҗалыктагы атларның баш саннарына чикләү бетерелде. Әлеге ярдәмне алыр өчен, маллар шәхси ярдәмче хуҗалыкларны теркәү кенәгәсендә күрсәтелгән булырга тиеш.

Бишенчедән, быел 1 апрельдән 1 июльгә кадәр сатып алынган **яшь кошкорт өчен субсидия** бирү яңартылды.

Белгеч фикере

Минталип МИНЕХАНОВ, фермер:
– Мин дә, тагын күп кенә фермерлар да эшчәнлегебезне 2000 нче елларда башлап җибәрдек. Ул вакытта хөкүмәттән бернинди дә ярдәм юк иде. 2010 елдан субсидияләр, грантлар була башлады. Алар бик кирәк, әлбәттә. Башлангыч вакытта аеруча зур ярдәм ул. Мәсьәләне тулысынча хәл итмәсә дә, эш башлар өчен стимул булып тора. Адәм баласы инде бер башлагач ничек тә тырыша ул. Тик соңгы елларда вазгыять безгә уңайга түгел. Татарстан грантлары бизнес-план нигезендә бирелә. Ярдәм күләме дә яхшы, рәхмәттән башка сүз юк. Тик, кызганыч, теләгән бөтен кеше дә алып бетерә алмый. Быел без дә грант алу бәхетенә ирештек. Тик аның өчен бизнес-планнарны 2021, 2022 елларда төзедек. Ул вакытта бәяләр башка төрле иде. Кыска гына вакыт эчендә металлга да, ягулыкка да, төзелеш материалларына да бәяләр бик нык артты. Шуңа күрә бәяләр арту нигезендә ярдәм итү чараларын уйларга кирәк. Минем үземә биш-алты капчык бәрәңге, берәр капчык кишер, чөгендер җитә. Калган барысы да халкыбызның табынына ризык булып бара. Ә фермерларга аның өчен бик тырышырга туры килә. Авырлыклары бар инде, әйтик, грантларны алу өчен дә хуҗалыкта бик белемле бухгалтер тотарга кирәк. Тик таш йөри-йөри шомара, диләр бит. Без дә хисләргә бирелмичә генә, башлаган эшебезне җиренә җиткереп эшләргә тиеш.

Алынган һәр үрдәк һәм каз бәбкәсе өчен хуҗалыклар – 200 сум, ә бройлер чебие өчен 100 сум күләмендә акча алды.

Моннан тыш, «Россельхозбанк» җәмгыяте үсемлекчелек, ит һәм сөт юнәлешендә терлекчелек, авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү өчен шәхси хуҗалыкларга сынау режимында **1 млн сумга кадәр кыска вакытлы (2–5 елга) инвестицияле кредитлар** бирә башлады. Ләкин монда хуҗалык башлыгының үзмәшгуль булып теркәлүе мөһим бер шарт булып тора.

Ярдәм чаралары турында язганда, **«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасы** турында да әйтми калу дөрес булмас. Бу программа кысасында республика узган ел – 2,1 млрд, быел 1,8 млрд сум акча алды.

– Әлеге программа төрле юнәлешләрне колачлый: торак, юллар, мәктәпләр, балалар бакчалары, спорт мәйданчыклары төзү, инженер-торак инфраструктурасын булдыру. Бу – авыл территорияләре өчен бик зур ярдәм, – ди Рөстәм Гайнуллов.

Фермерларга – федераль грантлар

Эшләрен яңа гына башлаучы аграрийлар арасында иң популяр грант – **«Агростартап»**. Ит һәм сөтчелек юнәлеше буенча эшләүче фермерлар мөгезле эре терлек үрчетү өчен – 5 млн сумга кадәр, ә калганнар 3 млн сумга кадәр грант алуда үзләрен сыный ала. Быел бу грантны 12 кеше алган. Акчаны бина салуга, җир кишәрлеге, махсус техника һәм җиһазлар сатып алуга тотарга мөмкин. Дуңгыз һәм кош-корттан кала, терлекләр алырга да рөхсәт ителә.

Авыл халкы **«Гаилә фермаларын үстерү»** грантында да актив катнаша. Бәйгедә җиңгән очракта, акчаны мөгезле эре терлек, кош-корт, балык, йорт куяны үрчетү һәм асрау, бакчачылыкны җәелдерүгә тотарга мөмкин. Мөгезле эре терлек үрчетү өчен грант суммасы бер хуҗалыкка 30 млн сумнан һәм чыгымнарның 60 процентыннан артык була алмый. Башка төр авыл хуҗалыгы хайваннарын үрчетү өчен бирелә торган иң зур сумма – 20 млн сум.

Авыл хуҗалыгы кооперативларына аның әгъзаларыннан **продукция сатып алу чыгымнарын каплау өчен ярдәм** дә бар. Быел бу максатларга Татарстанда 315 млн сум акча бүлеп бирелгән. Аның максаты – кооперативларга яңа әгъзалар җәлеп итү. Һәр яңа кеше өчен оешмага 100 мең сум бирәләр. Быелдан субсидиягә гаризаны кооперативлар гына түгел, ә халыктан сөт, ит (дуңгыз итеннән тыш) һәм яшелчә сатып алып эшкәрткән башка кешеләр дә тапшыра ала. Хәзерге вакытта республикада халыктан җыйган сөтне эшкәртүче 17 кооператив эшли.

Моннан тыш, федераль казнадан акча **«Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» грантына** да бүлеп бирелә. Быел әлеге бәйгедә республиканың ике кооперативы җиңеп чыкты.

Республика ярдәме

Быел республика бюджетыннан хуҗалык итүнең кече формаларына ярдәм йөзеннән 700 млн сумга якын акча тотылган. Ел саен **иң яхшы фермер, шәхси хуҗалык, авыл советы һәм кооперативлар**ны сайлыйлар. Җиңүче 100 мең сум акча белән бүләкләнә. Быел мондый уңыш 100 кешегә тәтеде. Иң төп шарт – мөгезле эре терлекләрнең баш санын киметмәү.

Шулай ук **кооперативларга сөтчелек фермалары төзү өчен** субсидияләр бирелә.

– Бу эштә Кукмара районының «Монокорм» һәм «Нәүрүз» хуҗалыкларына тиңнәр юк. Алар инде 244 сыерга 10 ферма төзеде. Мини-фермалар шәхси хуҗалыкларга арендага тапшырылды. Һәр фермага 3 млн сум күләмендә субсидия бирелде. Быел тагын шундый 17 мини-ферма төзү планлаштырыла, – диде Рөстәм Гайнуллов.

Быел **эшләрен яңа гына башлаган кооперативларга ярдәм** дә яңартылды. Әгәр 2018–2019 елларда грант күләме 5 млн сум белән чикләнсә, хәзер аны 10 млн сумга кадәр күтәрделәр.

Белеп тор!

Грант алу җиңел эш түгел, чөнки барлык шартларны, документларны да белгечләрдән, җитәкчеләрдән торган махсус комиссия карый. Кайберәүләр, әнә шул мәшәкатеннән куркып, гариза бирергә батырчылык итмәскә дә мөмкин. Тик күпләр Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы карамагында «Компетенцияләр үзәге» учреждениесе эшләвен белми. Биредәге белгечләр документларны бушлай тутырырга ярдәм итә. Шулай ук фермерлар районнардагы авыл хуҗалыгы идарәләренә, республиканың Фермер һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясенә һәм аның районнардагы филиалларына да мөрәҗәгать итә ала. Билгеле булганча, соңгы өч елда шәхси хуҗалыклар, субсидия алыр өчен, «Мои субсидии» сервисыннан да оста файдалана башлады. Тик әлегә бу сервис фермерлар өчен уңайлы түгел. Министрлык белгечләре киләчәктә алар өчен дә уңайлы булсын дип тырыша.

Сан

Быел Татарстанда хуҗалык итүнең кече формалары федераль казнадан – **575** млн сум, республика бюджетыннан **696** млн сум акча алачак.
Республикада **4** мең фермер хуҗалыгы, **474** мең шәхси хуҗалык һәм **336** авыл хуҗалыгы кооперативы эшли.

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

ЯЛГЫЗ БИЮ

БӘХЕТ ӨЧЕН КЕШЕГӘ... КЕШЕ КИРӘК ТҮГЕЛ?!

«Татар-информ»

Фикер

Алексей ЕГОРОВ, фәннәр кандидаты, социолог:
– Хәзерге икътисадый һәм социаль тормыш шартлары, бигрәк тә зур шәһәрләрдә, беренче карашка, ялгызлык проблемасын юк итә дә кебек. Бездә барысы да төгәл график буенча бара, ярдәм кирәксә, махсус хезмәтләр бар. Алар төшке ашны да өйгә алып килә, диварга киштә дә беркетә, бала белән шигырь дә ятлый. Түлә генә!
Күпчелекнең шәхси тормышы икенче планга күчә: үзеңне генә тәэмин итү, үз хыял-максатларыңны канәгатьләндерү күпкә арзанрак. «Һәр кеше үзе өчен җавап бирә» дигән принцип билгеле бер бәһагә ия. Ә бу – куркыныч күренеш. Аерым шәхес өчен дә, гомумән, җәмгыять өчен дә. «Шәхеснең бәхете җәмгыятьтән тыш мөмкин түгел», – дигән бит Лев Толстой да. Ялгызлык сәламәтлек өчен дә начар. Моны хәтта белгечләр дә, саннар да раслый.
(«Вечерняя Москва»га сөйләгәннәреннән)

Аңлы ялгызлык. Хәзерге көндә күпләр тормыш итүнең шундый юлын сайлый. «Аңлы» сүзен юкка гына өстәмәдек: ирек һәм бәйсезлек сайлап, гаилә кору һәм нәсел дәвам итүдән баш тарту, максатчан рәвештә барлык төр мөнәсәбәтләрдән үзеңне читләштерү турында сүз. Ялгыз булу кулаймы? Кешегә кешенең кирәге юкмы, ялгызлык куркытмыймы? Шул сорауларга җавап табарга тырыштык.

Сайлап алган ялгызлык

Фәнни терминологиясез булмас, билгеле. Аңлы рәвештә мөнәсәбәтләрдән, даими очрашулардан, гаилә корудан баш тарткан кешеләрне «сингл» дип атыйлар. Бер кешедән торган «гаилә» ягъни.

Күз күреп, колак ишетеп ияләшкән ялгызлар белән бутарга ашыкмагыз. Синглар (яисә синглтон) ялгызлыктан, парсыз калудан интекми, зар еламый, бәлки киресенчә, бу халәттән ләззәт кичерә. Аларга бәхетле булу өчен мөнәсәбәтләр кирәк түгел ягъни. Россиядә һәм дөньяда ничә сингл барлыгын беркем дә төгәл белми, әлбәттә. Ләкин белгечләр фикеренчә, аларның саны елдан-ел арта бара. Өстәвенә нигездә 18 яшьтән 34 яшькә кадәрге яшьләр хисабына!

Зәлидә Сафиуллина да (әти-әнисе танымасын өчен, исемен үзгәртүне сорады. – **Авт.**) үзен синглтон дип атарга нигез бар, ди. Казанның төзелеш техникасын арендага бирү фирмасында финанс мәсьәләләре буенча белгеч булып эшли ул. 25 яшен тутырган. Бер тапкыр да кияүдә булмаган, җитди итеп бер тапкыр да егетләр белән очрашмаган, озак вакытлы мөнәсәбәтләргә кергәне юк.

– Битемнән үптергәнем дә, убешкәнем дә юк хәтта *(көлә)*! Минем өчен, миннән кала бөтен кеше борчыла инде, – дип шаярта әңгәмәдәшебез. – «Ялгызың калсаң, бер дә рәхәт булмас», «Картлык көнеңдә яныңда кеше кирәк», «Бала табарга кирәк» ише сүзләрне көн дә ишетмәсәм дә, еш ишеттерәләр. Бигрәк тә әти-әнигә басым ясыйлар. Алар миңа бәйләнә. Ярый әле гаиләдә бердәнбер бала түгелмен. Шөкер, миннән олырак абыем һәм апам бар. Алар инде гаиләле, сабыйлар үстерәләр. Мин – ул балаларга менә дигән тәти апа! Шул да җиткән.

Зәлидә сүзләренчә, аның бер кешегә дә баш-аягы белән гашыйк булганы юк. Югыйсә артыннан егетләр дә аз йөрмәгән.

– Университетта икътисад юнәлеше буенча белем алдым. Төркемдә егетләр күп иде. Татарлары да, башкалары да дигәндәй. Һәрберсе үк булмаса да, яртысы мәхәббәт аңлатып чыкты инде. Бүләкләргә дә, чәчәкләргә дә күмделәр, кинога да дәштеләр. Әмма мин кырт кисә идем. Күңелсез булганда гына берәр кая барган, аларны җәлләп кенә бүләкләрен алган чакларым хәтердә. Йөрәккә дә, аңга да әмер бирә алмыйм бит, миңа бу кызык булмады һәм хәзер дә кызык түгел, – ди Зәлидә.

Иптәш кызларының күбесен кияүкулларына тапшырган инде ул. «Аларның бер-бер артлы гаилә корып, тормышымнан акрынлап югала баруларына да аптырамыйм. Кем нинди юл сайлый инде. Мин иргә ашарга пешереп, тәти хатын булып яшәргә, каенана-каенатага ярарга теләмим. Аннары балалар сорый башларлар... Кемгәдер бәйле һәм тиеш буласы килми, бары шул. Миңа үзем белән дә бик рәхәт! Эштән кайтып керәсең, ни теләсәң, шуны эшлисең, контроль юк! Чын ирек! Ирекне берничә дә алмаштырып та, тиңләп тә булмый!» – ди ул.

Үзен тулысынча карьерага багышламакчы хәзер. Эшендәге җитәкчесе дә яхшы гына хезмәт хакы һәм яңа вазыйфа тәкъдим иткән.

– Әлегә үз куышым юк. Фатир, иң яхшысы, шәһәр читендә йорт аласым килә! Шуңа акча җыям. Мөнәсәбәтләргә вакыт та, акча да сарыф итәсем килми, – ди Зәлидә.

Сәбәпләре нидә?

Гаилә төшенчәсенең әһәмияте киму, шәхеснең мөстәкыйльлеге, тормыш сыйфатының үзгәрүе, көнкүрешне җиңеләйтүнең яңа алымнары барлыкка килү, социаль челтәрләр, гадәтләнгән тормышыңа башка кешене кертергә теләмәү – болар барысы да кешене кешедән ерагайтуга сәбәпче.

Психолог Ирина Комарова сүзләренчә, аңлы ялгызлыкны сайлаучыларның күбесе – иҗат кешеләре, карьера баскычыннан үрмәләүчеләр, мөстәкыйль, җитлеккән шәхесләр. Аларның үз-үзен тотышында еш кына балалык эгоизмын һәм эгоцентризмны (үзәктә – «мин») күрергә мөмкин. Синглтоннарны да берничә төргә бүлеп карарга була.

– «Җиңел акыллы»лар, гадәттә, үз рәхәте өчен генә көн күрә. Алар эш дип тә, карьера дип тә чапмый. Гадәттә, андыйларны ата-анасы тәэмин итеп тора, – ди белгеч. – «Карьерист»лар бар игътибарын үз юлын, урынын табарга юнәлтә. Әйтик, фән хезмәткәрләре. Алар баш-аягы белән бу өлкәгә чумган. Гадәттә, бу төркемгә кергән кешеләр барысы да нәсел калдырырлык яшьтә һәм хәлдә.

Социология фәннәре кандидаты Чулпан Илдарханова әйтүенчә, социаль ялгызлык шаукымы – хәзерге заманның бәласе. Моны тикшерүләр китергән саннар да сөйли.

– Тәбәктә 16 яшьтән өлкәнрәк потенциаль кәләшләр 43,4 процентны тәшкил итә. 16 яшьтән өлкәнрәк булган ир-атларның 22 проценты беркайчан да өйләнеп карамаган. Тагын алты проценты – аерылганнар, дүрт проценты – тол калганнар, – ди белгеч.

Дус булса, бер сәгатькә булсын!

Килеп җиттек, диярсең: хәзер дусны да... арендага алырга мөмкин, ди. Кинога, кунакка, паркка, кеше янына чыкканда ялгыз булып күренергә теләмәсәң, тик шул үк вакытта ирекле булып калырга теләсәң, акча түлә. Мондый хезмәт хәзерге көндә бик популяр. «Авито» хезмәтенең мәгълүматларына караганда, коронавирусны чорда мондый тәкъдимнәр игъланнар сайтында өчләтә арткан! Күпчелек «дус-иш»ләрнең психологик белеме бар. Кирәк икән, тыңлыйлар, кирәксә – дәшмиләр. Алга таба дуслашып китү мөмкин дә түгел: рольләр билгеле, акча түләнгән, барысы да килешенгән план буенча бара.

«ВТ» хәбәрчесе дә якшәмбе көнгә шундый «дус» эзләп карады. «Мөнәсәбәт корырга, дуслашырга теләк тә, вакыт та юк. Кеше янында «ялгыз икән» дигән даным чыкмасын өчен, янымда йөрергә ир-егет кирәк», – дигән соравыма үз «хезмәте»н Казан егете Илья тәкъдим итте.

– Мин сөйләшергә яратам, теләсә нинди компаниядә үземне яхшы яктан күрсәтә алам, тел яшермим, – диде ул. – Тормышым вакыйгаларга бай, шуңа күрә кешегә сөйләрлек тарихларым да күп. Кызыксынуларым җитәрлек. Әйтик, мотоцикллар белән мавыгам.

«Дус» булу хакы да әллә ни зур түгел – сәгатенә 400 сум. «Әмма мин бу «эш»кә акча эшләр өчен алынмадым. Миңа чынлап та танышулар, аралашулар ошый. Кайчагында артык кызыксынучан да булам», – ди егет.

Сан

➤2021 елда уздырылган Бөтенроссия халык санын алу бер кешедән генә торган 27,6 млн йорт хуҗалыгы барлыгын ачыклаган.
➤Гасыр башыннан ялгызлар өлеше ике тапкыр диярлек арткан.

P.S. Язма әлеге күренешне пропагандалау түгел, күренеш буларак тасвирлау максатын күздә тотып әзерләнде.

Сәрия МИФТАХОВА

СОҢГЫ МОГИКАННАР

Илдар Мөхәммәтҗанов

Иске авылга яңа төс өстәп тора әлеге кое. Нургали Миңнеханов эшләгән урманчылык заманасында Кызыл Йолдыз урманчылыгына караган. Моннан берничә ел элек аның истәлегенә шушы нигезне койма белән әйләндереп куйганнар. Бик матур итеп бурадан кое ясаганнар.

Теләче

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Гороховтан башланганмы?

Республика авыллары атамалары турындагы китапны актарганда, Борчаклы Яз дигән исемгә игътибар иттек. Кызык, мондый авыл да бармы икән? Бер дә ишеткән юк. Белешә торгач, анда ике генә гаилә яши булып чыкты. Рөстәм Миңнехановның әтисе Нургали абый шул урманчылыкта эшләгән икән. Саба районы башлыгы Рәис Миңнеханов Борчаклы Язда туган. Тарихи авыл булып чыкты түгелме соң әле бу? Барып карыйк әле, дидек.

Теләче районының Айдар җирлегенә карый әлеге авыл. Борчаклы Яз (Гороховое Поле) авылының килеп чыгуы турында берничә төрле мәгълүмат бар. Беренчесе – Субаш авылыннан керәшеннәр күчеп утыруга, икенчесе Горохов фамилияле сөргенгә сөрелгән кешенең килеп төпләнүенә бәйле булырга мөмкин. Соңрак авылга күрше-тирә районнардан руслар килеп урнашкан. Элек чиркәве дә булган, тик аны сүтеп алып киткәннәр. Халык телендә, авылда күп мәйданда борчак иккәннәр, дигән версия дә бар. Халкы игенчелек, терлекчелек, умартачылык, бакчачылык белән шөгыльләнгән.

Борчаклы Язда 1879 елда земство мәктәбе ачылган, биш сәүдә ноктасы эшләгән. Мәктәп, кибет, клуб, медпункт, ферма... Барлык социаль объектлары да булган, кыскасы. Районда беренчеләрдән булып телефон кертелгән. 1906 елда мәктәптә 50 бала белем алган. 1908 елда – 741, 1938 елда 501 кеше яшәгән. Әкренләп йорты да, кешесе дә кимегән. Соңгы 7 елда 3 кеше гомер итә.

4 мең йомыркалы кибет кыйссасы

Авылда хәзер, әнә тегендә – мәктәп, ферма, әнә тегендә контора иде, дип бушлыкка төртеп сөйләргә генә калган. Ул җирләрдә каты кура үсә. Ә элеккеге гасыр кичкән бер таш бина һаман да ишелми икән. Югыйсә җимереп тә караганнар үзен. Шулай бик нык булганга күрә авыл халкы, 400 мең йомыркадан эшләнгән ул, дип сөйлиләр. «Юк, булмас», – дисәм дә, үзләренеке хак. Бай өе соңрак авыл халкына кибет булып хезмәт иткән.

– Юк, 400 мең түгел, 4 мең йомыркадан эшләгән. Элек, бина нык булсын өчен, измәгә шуны кушканнар. Яңгыр гына юып җибетсә инде, – ди Айдар авыл җирлеге башлыгы Хәйрулла Хәсәншин.

Субаш авыл клубы мөдире Татьяна Романова – шушы авыл килене. Ул сатучы булып эшләгән. «Бу иске кибеттә түгел, лавкада», – диде. Хәзер авылдашлары кирәк-яракка күрше авылга йөри.

Урамнар буйлап...

Авылда өч кенә йорт бар, дидек. Иске, сорысы, җиргә иңгәне – Жуковларныкы. Икенчесендә Валентина Ивановна яши. Өч ел элек Лаеш якларыннан күченеп килгән. Ә өченчесе – умартачы Игорь Максимовныкы. Гаиләсе белән Казанда яшәсә дә, туган нигезен тәртиптә тота.

Безне авыл буйлап озатып йөрүчеләр – Лидия Агафонова белән Владимир Жуков. Таякка таянып булса да, кирәклесен күрсәттеләр, рәхмәт. 40 ел бер түбә астында гомер итәләр икән. Тик паспортка мөһер сугуны кирәк дип тапмаганнар. Лидия апага – 72 яшь. Ул иреннән 7 яшькә олырак. Лидия мәктәпне тәмамлагач, Казанга заводка эшкә урнашкан була. Кияүгә чыгып, ике бала тапкан. Тик никахлары озын гомерле булмаган. Шулай итеп, авылга кайтырга туры килгән. 34 яшендә икенче тапкыр бәхетен сынап караган ул. Кызганыч, уртак балалары суга батып үлгән. Әмма Лидия ханымның балалары аларны ташламый. Кайтып, хәлләрен белешеп торалар икән.

Рус милләтеннән булса да, Володя дәдәй татарча сөйләшә. «Белмәскә, мин бит Нырсы мәктәбендә белем алдым», – дип җибәрә. Ә менә Субаш мәктәбендә укыган Лидия түтәй, теләсә дә, татарча өйрәнә алмаган.

– Мин лаеклы ялга чыкканчы, фермада сыер саудым. Аннан ферманы бетерделәр. Эш беткәч, авылдашлар читкә китү ягын карады, – дип сөйли авылның соңгы могиканнарының берсе.

Владимир Жуков әйтүенчә, элек Борчаклы Язда 170тән артык йорт булган. «Елганың бер ягында – бер, икенче ягында икенче колхоз иде, дип сөйли иде өлкәннәр. Без үскәндә, йортлар саны артык күп түгел иде инде», – ди абзый.

Әкренләп элек урманчылык булган якка таба атладык. «Әнә күрәсеңме теге матур коены? Рәис Рөстәм Миңнехановның әтисе Нургали абыйларның нигезе ул. Монда берничә ел эшләгәч, аны Саба урман хуҗалыгына директор итеп билгеләделәр. Саба районы хакимияте башлыгы Рәис Миңнеханов шушы авылда туды. Моннан киткәндә, аңа 1 яшь чамасы булгандыр. Авылга килгәндә, безнең белән күрешеп киткәли», – ди Володя дәдәй.

Яшәүләре ничек?

Жуковлардан яшәү шартлары турында да, «Күңелсез түгелме?» – дип тә сораштык.

– Көнебез телевизор карап үтә. Җәй көне кеше күп булганда рәхәт. Буран чыкканда күңелсез шул. Моңсуланып алабыз. Тик авыл җирлеге башлыгы Хәйрулла юлларны ачып тора, рәхмәт яугыры. Кибеткә барасы бар бит. Берничә тапкыр ашыгыч ярдәм чакырырга да туры килде. Юллар ачык булганда кыенлык тумый, – ди ул.

Авылның иң күңелле вакыты – Тройсын (Троица) бәйрәме узган чак. Борчаклы Язга авылдашлар кайта. Каенның яшел ботакларыннан «киенеп», биеп, җырлап күңел ачалар.

Хәйрулла Хәсәншин, колхоз рәисе булып эшләгәндә, авылга кадәр газ суздырган. Тик берничә кеше генә яшәгәч, зәңгәр ягулык өйләргә кадәр барып җитә алмаган. Йортларын утын ягып җылыталар. Суга исә чишмәгә йөриләр.

– Авылның табигате матур. Яшәү урыны белән кызыксынучылар да бар. Бәлкем, күчеп килүчеләр дә булыр. Борчаклы Яз зурайган очракта йортларга газ да керер, кем белә, – дип өметләнә башлык.

Башкалар киткәч...

«Ник киттегез, ник авылда калмадыгыз?» Туган авылында яшәмәүчеләргә бирдек без бу сорауны.

– Мин 39 яшькә кадәр шушында гомер иттем. Субаш авылында механизатор булып эшләдем. Хәзер дә шунда хезмәт куям. Хатыным Татьяна белән монда 13 ел яшәдек. 1973 елда совхозлар күмәкләшкәч, авылдашлар төрле җирләргә күчеп китте. Урманчылык та бетте. Эш калмады. Безгә эш урыны буенча күрше авылда бушлай фатир бирделәр. Туган йортым искерде инде, сүтәсе бар. Әти-әни яшәгән нигезне сүтәргә кул да бармый. Үткәннәр истәлеге бит ул, – ди Валерий Романов.

Сүзгә Татьяна кушылып: «Килен булсам да, бик яраттым мин бу авылны. Йокларга яткач та искә төшерәм. Ул чакта 13ләп йорт бар иде. Сыер, сарык көтүләре чыга иде, – ди. – Авыл беткәч, без дә күчендек инде. Кеше калмады бит. Балалар күрше авылга җәяү йөреп укыды. Автобуслар юк иде әле. Мөмкинлекләр кирәк бит. Аларның киләчәге турында да уйладык».

Жуковлар исә беркая да китәргә җыенмый. «Монда тудык, монда үстек. Беркая да китмибез. Иң матур, иң якты авыл ул Борчаклы Яз», – ди патриотлар. Нинди генә булса да, кадерле шул туган авыл!

2 октябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.10 «УКЫТУЧЫЛАР». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+». Как распознать ложь? Интервью с Региной Гайсиной 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» һәм «Учимся вместе» 0+
17.30 «Ватандашлар» 16+
18.00, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
23.00 «СЕМЕЙНЫЙ ДОМ». Телесериал 16+
00.00 «Соотечественники» 16+
00.25 «Каравай». Поволжские сказы 6+
00.50 «Таяну ноктасы» 16+
01.15 «Нәсыйхәт» 16+
01.40 «Путь» 16+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлар белән) 16+
04.45 «Точка опоры» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Родная земля» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Саҗидә Сөләйманова турында телеочерк 16+
15.20 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
18.20 «Башваткыч» 12+
19.10, 22.10, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Калеб» 6+
21.55 «Туган авылым» 12+
23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Ватандашлар» 16+
03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Саҗидә Сөләйманова турында телеочерк 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Премьера. «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское» 16+
17.00 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Ольга Сутулова, Кирилл Кяро. «СПРОСИ МАРТУ» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
01.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
02.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
02.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Премьера. «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Игорь Петренко, Александра Никифорова, Ольга Красько, Александр Ратников. «ДОКТОР КРАСНОВ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Анна Ковальчук. «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.15 «Игра миллионов» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.10, 12.55, 14.45 Новости
07.05, 18.30, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.15, 12.35, 00.35 Специальный репортаж 12+
10.35 «Легендарные клубы» 12+
11.35 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 6+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.50 «География спорта. Волгоград» 12+
15.20 «Громко». Прямой эфир
16.25 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Акрон» (Тольятти) – «Химки» (Московская область). Прямая трансляция
19.00 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Спартак» (Москва) – «Локомотив» (Ярославль). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Чемпионат Италии. «Фиорентина» – «Кальяри». Прямая трансляция
00.55 Гольф. Континентальная гольф лига. Трансляция из Московской области 0+
02.55 Новости 0+
03.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «МИНСК» (Белоруссия) – «Пари Нижний Новгород» 6+
05.00 Кудо. Кубок дружбы на призы губернатора Калининградской области 16+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 9.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
22.15, 00.00 Сергей Шаталов и Татьяна Рассказова в детективном сериале «ДАЙВЕР» (S) 16+
00.50 Андрей Бурковский, Юлия Пересильд, Дарья Мороз в детективном сериале «МЕДИАТОР» (S) 16+
03.20 Сериал «ГЛАЗА В ГЛАЗА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.35 «Давай разведёмся!» 16+
08.35 «Тест на отцовство» 16+
10.45 «Понять. Простить» 16+
11.55 «Порча». «Синдром Бога». «Позолота» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «Преступления страсти» 16+
19.00 «СЛИШКОМ БЛИЗКО, СЛИШКОМ БОЛЬНО» 16+
22.55 «Понять. Простить» 16+
00.00 «Порча» 16+
01.00 «Знахарка» 16+
01.25 «Верну любимого» 16+
01.55 «Голоса ушедших душ» 16+
02.20 «Тест на отцовство» 16+
04.00 «Преступления страсти» 16+
05.35 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

04.10 «УЗНИК ЗАМКА ИФ». Телесериал (СССР, Франция, 1988). Фильмы 2-й и 3-й 12+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 01.15 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». Телесериал. «Мы наш, мы новый...» 1-я серия 12+
12.30, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
12.45, 19.55 «По горячим следам» 16+
13.25, 15.05, 17.15 «ОТРЯД КОЧУБЕЯ». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Оружие холодной войны». Документальный сериал. «Артиллерийская дуэль». Премьера 16+
20.10 «Ищу своих». Премьера 12+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «БЕЛОРУССКИЙ ВОКЗАЛ» 12+
02.25 «ПРИКАЗАНО ВЗЯТЬ ЖИВЫМ» 12+
03.55 «ОТРЯД КОЧУБЕЯ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

3 октябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». К 100-летию Р.Г. Гамзатова 16+
11.15 «Если хочешь быть здоровым» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «УКЫТУЧЫЛАР». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Семь дней+». Театральное училище: развитие и перспективы. Интервью с Руфиной Тазетдиновой 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» һәм «Учимся вместе» 0+
17.30 «Заман көзгесе» 6+
18.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.00 Новости Татарстана 16+
19.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Северсталь». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.00 «СЕМЕЙНЫЙ ДОМ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК». Телевизион нәфис фильм 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлар белән) 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...»т 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.20 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
18.20 «Җырлыйк әле!» 12+
19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Рәмис Аймәт турында телеочерк 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское» 16+
17.00 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. «СПРОСИ МАРТУ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «1993. Осень в огне» 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
01.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Анекдоты» 16+
04.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Премьера. «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Игорь Петренко, Александра Никифорова. «ДОКТОР КРАСНОВ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.15 «Игра миллионов» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 10.10, 12.55, 14.45 Новости
07.05, 19.15, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.15, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.35 «Легендарные клубы» 12+
11.35 «Вы это видели» 12+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.50 Футбол. FONBET Кубок России. «Урал» (Екатеринбург) – «Рубин» (Казань). Прямая трансляция
17.00 Футбол. FONBET Кубок России. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Балтика» (Калининградская область). Прямая трансляция
19.30 Футбол. Лига чемпионов. «Зальцбург» (Австрия) – «Реал Сосьедад» (Испания). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Лига чемпионов. «Наполи» (Италия) – «Реал» (Мадрид, Испания). Прямая трансляция
00.55 Футбол. Лига чемпионов. «Манчестер Юнайтед» (Англия) – «Галатасарай» (Турция) 6+
02.55 Новости 0+
03.00 Регби. PARI Чемпионат России. «Стрела» (Казань) – «Енисей-СТМ» (Красноярск) 12+
05.00 Спортивная гимнастика. Чемпионат мира. Трансляция из Бельгии 6+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
22.15, 00.00 Детективный сериал «ДАЙВЕР» (S) 16+
00.50 «МЕДИАТОР» (S) 16+
03.15 «ГЛАЗА В ГЛАЗА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.15 «Давай разведёмся!» 16+
08.15 «Тест на отцовство» 16+
10.25 «Понять. Простить» 16+
11.30 «Порча». «Разыскивается девочка». «Печать мертвеца» 16+
12.35 «Знахарка» 16+
13.10 «Верну любимого» 16+
13.45 «Голоса ушедших душ» 16+
14.20 «Твой Домашний доктор» 16+
14.35 «Преступления страсти» 16+
19.00 «ЗАБЫТЫЙ РЕЦЕПТ ЛЮБВИ» 16+
22.55 «Понять. Простить» 16+
00.00 «Порча» 16+
01.00 «Знахарка» 16+
01.25 «Верну любимого» 16+
01.55 «Голоса ушедших душ» 16+
02.20 «Тест на отцовство» 16+
04.00 «Преступления страсти» 16+
05.35 «6 кадров» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «ОТРЯД КОЧУБЕЯ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 01.00 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». Телесериал. «Мы наш, мы новый...» 2-я серия 12+
12.30, 18.50 «Спецрепортаж» 16+
12.45, 19.55 «По горячим следам» 16+
13.25, 15.05, 17.15, 03.15 «ОТРЯД КОЧУБЕЯ». Телесериал. 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Оружие холодной войны». Документальный сериал. «Ядерные хот-доги». Премьера 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ПРОПАВШИЕ СРЕДИ ЖИВЫХ» 12+
02.10 «Нюрнберг». Документальный сериал 16+
02.50 «Хроника Победы». Документальный сериал 16+



ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНҮ, ДӘВАЛАНУ ҺӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ ҺӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ ҺӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР ҺӘМ ГАРАНТИЯЛӘР



ТҮБӘНЕ ДӘ, ЮГАРЫСЫ ДА КУРКЫНЫЧ

Саулык сынатуның беренче билгесе ул. Ул күтәрелгәндә бөтен гәүдә сызлый, күзләр әчетә, калтырата... Сүзебез тән температурасы турында. Ул күпме булырга тиеш? Градусник 35,5 градус күрсәтсә, чаң сугарга кирәкме?

Республика клиник хастаханәсе табиб-терапевты Анастасия ЯКОВЛЕВА тән температурасына бәйле сорауларыбызга җавап бирде.

:: Температура нинди чирләр вакытында күтәрелә? Әгәр тән температурасы даими рәвештә 37 градустан югары чиктә сакланса, чаң сугарга кирәкме?

– Температура тәннең җылылык күрсәткече санала. Аның югары булуы – үзе үк чаң сугарга җирлек. Ул даими рәвештә сакланса, бигрәк тә. Кичекмәстән аның күтәрелүенә китергән төп сәбәпне эзләргә – табибка күренеп, анализлар тапшырырга кирәк. ОРВИ, бронхит, пневмония кебек чирләр вакытында тән температурасы күтәрелү гадәти күренеш санала. Бактериаль, вируслы, паразитар, аутоиммун авырулар, яман шеш, ВИЧ, аллергия, сепсис (кан ялкынсыну) вакытында, эчәклектә, калкансыман бездә хилафлыклар булганда да температура югары була. Даими рәвештә стресс, невроз халәтендә яшәгән кешенең, хатын-кызларның климакс, йөклелекнең беренче триместры чорында да температура даими күтәрелә ала.

:: Бүген температураны терекөмешле градусник белән генә түгел, авыз, маңгай, колакка куела торган махсус җиһазлар ярдәмендә дә үлчәп була. Аларның кайсы төгәлрәк күрсәтә?

– Хәзер аларның барысы да нәтиҗәле. Өлкәннәр өчен элек-электән кулланылган терекөмешле градусник яхшы санала. Ул балаларның тән температурасын үлчәү өчен дә кулланыла. Моннан тыш сабыйлар өчен чыгарылган электрон, имезлек сыман термометр да төгәл үлчи.

:: Кайчак градусник кеше өчен норма саналган 36,6 градустан да түбәнрәк саннар күрсәтә. Бу ни сәбәпле шулай? Әйтик, тән температурасы 35,5 градус булса, хәвефләнергә кирәкме?

– Вегетатив кан тамырлары дистониясе, калкансыман биз, Адиссон авыруы (гипотериоз) вакытында, кандагы глюкоза күләме азайганда (гипогликемия), гемоглобин түбән булганда, бөер өсте бизләре дөрес эшләмәгәндә дә температура бик түбән була.

:: Температура күтәрелгәндә нәрсә эшләргә ярамый?

– Андый чакта иң беренче чиратта азрак хәрәкәтләнергә, физик эш-күнегүләрдән тыелып торырга кирәк. Мөмкин кадәр күбрәк чиста, җылы су эчәргә тырышыгыз. Алай эшләгәндә температура тизрәк төшәчәк. Бүлмәне җилләтеп, салкын компресс ясау да температураны төшерергә ярдәм итәчәк. Температура югары булганда мунча, кайнар ванна керергә, спирт белән компресс ясарга ярамый.

pinterest.com

ТЕМПЕРАТУРА КҮТӘРЕЛГӘНДӘ НИЧЕК ТУКЛАНЫРГА?

Ашарга	
ярый	ярамый
яшелчә/җиләк-җимеш	кыздырылган/майлы ризыклар
чиста су, газсыз су, яшел чәй, яңа сыгылган сок	каһвә/исерткеч эчемлекләр
шулпа, парда пешкән ризыклар	ысланган/тозлы ризыклар
җиңелчә ит, балык ризыклары	сөт
кузаклылар	ярымфабрикат ризыклар
С витаминына бай ризыклар	фасоль

:: Температура нинди чиккә җиткәч, аны дарулар ярдәмендә төшерергә рөхсәт ителә?

– Температура күтәрелгәндә, вирус һәм бактерияләр акрынрак үрчи башлый. Әмма ул 38,5 һәм аннан да югарырак чиккә күтәрелгәч, аны тиз арада төшерергә кирәк. Юкса җитди өзлегүләр башланырга мөмкин.

:: Халык медицинасы ысуллары турында ни диярсез?

– Температураны махсус дарулар ярдәмендә төшерүдән дә яхшысы юк. Халык медицинасы алымнарының, бигрәк тә составында шикәр булган төнәтмә-ризыкларның әллә ни файдасы юк. Шифасы булмаудан тыш әле алар аллергия дә китереп чыгарырга мөмкин.

Киңәш

АНГИНАНЫ ДӘВАЛЫЙБЫЗ

depositphotos.com

✓Каен ботаклары төнәтмәсе. Сындырылган, изелгән бөреле ботаклар өстенә кайнар су коеп, 1 сәгать төнәтергә. Көненә берничә стакан эчәргә мөмкин. Тик бөерләре шешкән кешеләргә моны эчәргә ярамый.

✓Лимон. Авыруның башлангыч чорында ярты лимонны кабыгы белән бергә ашыкмый гына ашап бетерергә. Шуннан соң 1 сәгать бернәрсә дә ашамаска, эчмәскә. Эфир майларына һәм лимон кислотасына тамакның ялкынсынган тышчасына тәэсир итү өчен шул рәвешчә уңай шартлар тудырыла. 3 сәгатьтән соң лимонны кабат ашарга була. Шулай ук 2–3 телем кабыгыннан чистартылган лимонны авызга кабып суырырга да мөмкин. Суын йота барырга. Моны җиңеллек сизгәнче һәр сәгать саен кабатларга кирәк.

✓Тома балавыз (умарта корты җилеме, прополис). Сырхауның барлык стадияләрендә дә файдасы тия. Ашап-эчкәч, авызга бармак очы хәтле генә җилемне кабып чәйнәргә; көненә барлыгы 5 г җилем таләп ителә. Җилемнең бик сыйфатлысы гына ярдәм итә. Андый җилем авызга капкач, көйдереп алгандай итәргә, телне оетып җибәрергә тиеш.

✓Куе арпа сыгынтысы. 1 аш кашыгы төйгән арпаны 1 стакан җылымса суга салып 4–5 сәгать төнәтергә. Шуннан соң 10 минут кайнатып сөзәргә. Көненә 4 тапкыр 1/4әр стакан эчәргә. Тамак бакасын дәвалаганда гына түгел, эчне йомшарту, өске сулыш юлларын дәвалау өчен дә файдалы ул.

Инҗирнең файдасы

Табигать даруханәсе

Инҗир яшелчәгә дә, җиләк-җимешкә дә керми. Ул – фикус ыругына керә торган үсемлек.

Аның җимешләре бик тәмле һәм гаять күп микъдарда файдалы матдәләрдән тора.

Инҗир С витаминына бай. Ә ул, инфекция һәм авыруларга каршы көрәшергә ярдәм итеп, иммун системасын ныгытуда зур роль уйный. Моннан тыш әлеге витамин, тән тиресенең тиз картаюына киртә куеп, коллаген торгызуга ярдәм итә.

Гөлнара Зиннәтуллина

Инҗирда антиоксидантлар да күп. Алар күзәнәкләрне онкологиягә, йөрәк-кан тамырлары авыруларына, Альцгеймер авыруына китердәй иреклe радикаллардан (атом кисәкчекләре) саклый.

Үсемлек җимеше составындагы тагын бер мөһим минерал – калий. Монысы йөрәк тибешен һәм кан басымын көйләү өчен кирәк. Шулай ук йөрәк-кан тамырлары авырулары куркынычын, кандагы холестерин микъдарын да киметә.

Инҗир составындагы җепселләр ашкайнатуга ярдәм итә, эч кибү кебек ашказаны-эчәклектәге проблемаларны юкка чыгара. Анда шулай ук магний, бакыр, тимер һәм А витамины күп. Бу матдәләр сәламәтлеккә уңай йогынты ясый, көч-энергия өсти, кәефне күтәрә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

КИСҮНЕҢ ДӘ БАР РӘТЕ

Бакчада җимеш агачлары һәм куакларын кирәкмәс ботакларыннан арындырырга вакыт. Үсемлекләргә зыян китермичә генә бу эшне ничек дөрес итеп башкарырга? Кура үсентеләрен кайчан кисәргә?

Бу хакта «Россельхозцентр» оешмасының Татарстандагы филиалы җитәкчесе урынбасары Гүзәл ХӨСӘЕНОВАдан белештек.

– Көзен агач ботакларын, яфраклары коелып беткәннән соң, согы хәрәкәтләнүдән туктагач кисәбез. Суыклар башланганчы, бу эшне төгәлләп куярга кирәк.

Иң элек сынган, җимеш бирмәгән һәм корыган ботакларны, аннары ябалдашның куерган, бер-берсенә тиеп торган ботакларын кисәбез, чөнки алар агачка яктылык төшәргә комачаулый. Агачны кәүсәдән өскә таба кыек-мыек үскән һәм кыргый ботакларыннан арындырабыз.

Шуны истә тотыгыз: берочтан бик күп эре ботакларны кисәргә ярамый. Бу агачны зәгыйфьләндерүгә яисә бөтенләй коруга китерергә мөмкин.

pinterest.com

Игътибар! Җәй ахырыннан көз урталарына кадәр көннәр коры торса, кышка керер алдыннан агач-куакларга су сибеп калдырырга кирәк. Ләкин бу эшне суыткач, һава температурасы +1...+3 градус чамасы булгач кына башкаралар. Юкса җылы вакытта су сибү бөреләнүгә китерергә мөмкин. Суны күп итеп, 60–80 см тирәнлектә туфракка үтәрлек итеп сибәбез. Су сибү агач-куакларның кышкы суыкларны җиңелрәк кичерүенә ярдәм итәчәк.

Кискәч, ботакның ярасына бакча сумаласы (садовый вар) яки майлы буяу сылыйбыз. Кису өчен бары тик үткен пычактан гына файдаланырга тырышыгыз. Ник дигәндә, үтмәс корал белән кискән урын озак төзәлә.

Кура үсентесенең корыган, сынган, бик нык сыгылган ботакларын кисеп ташлагыз. Җиләк биргән ботакларының очын кыскартыгыз. Мондый үсенте сабакларының түбәнге өлеше коңгырт төстә була.

Укучы киңәше

Сарымсак сортын яңартам

Сарымсак утыртырга вакыт җитеп килә. Аны октябрь урталарына кадәр җиргә кертү әйбәт. Кышка сарымсак утыртып калдыру буенча үз тәҗрибәм белән уртаклашасым килә.

Сарымсак тешләреннән тыш, аның берьеллык суганчаларын да утыртам. Нәрсә соң ул, дисезме? Моның өчен иң элек укларында хасил булган орлыкларын тәмам өлгереп җиткәч кенә җыеп алам. Шуннан соң язын утыртам. Җәй эчендә алар үсеп, суганчаларга әйләнә. Сүз уңаеннан, бер уктан 40–50 данә орлык җыеп алырга мөмкин, шуңа күрә укларны күп калдырырга кирәкми.

Вакытлар узуга, сарымсакның теләсә кайсы сорты сыйфатын үзгәртә, вагая, авырый башлый. Ә менә беренче елында орлыктан суганча үстереп, икенче елында аны утырту сарымсакның сортын яңартуга китерә. Мондый сарымсак эре була, әйбәт саклана. Тик уңышы икенче елда гына җыеп алына.

Әлфинур НӘҖМЕТДИНОВА. Казан

Шекспирны яратам

Һәр ел саен октябрь аенда кышка суган утыртмыйча калганым юк. Шекспир, Сеншуй, Даниловский һәм Кип-Велл сортларына өстенлек бирәм. Көндез һава температурасы +5 градус чамасы торса, димәк, бу эшкә тотынырга вакыт, дигән сүз.

Язын су җыелып тормаслык урында түтәл ясыйм. Кабак, бәрәңге һәм кәбестәдән калган җирдә суган бик әйбәт үсә. Түтәлгә тирес урынына компост кертү әйбәт. Бер-берсеннән 15 см ераклыкта буразналар ясыйм. Орлыкларны суга салып тормастан, 4 см ара калдырып, 5 см тирәнлеккә утыртам. Утырткач, су түгел, ә компост белән торф катнашмасы сибәм. Шуннан соң түтәл өстен пычкы чүбе, яфрак, салам белән каплыйм.

Язын, туфрак кояшта җылынсын өчен, түтәл өстен алам. Тирес суы сибәм. Суганнар күз алдында гөрләп үсеп китә!

Г. ЗАРИПОВА. Арча

Кышка әзерлек

Гөмбәдән хуш исле солянка

vk.com

Рәмзия ГАТАУЛЛИНА рецепты

Яртышар литрлы 10 банка солянка ясау өчен кирәк булачак: 1 кило кәбестә, 1 кило помидор, 1 кило кишер, ярты кило башлы суган, 2 кило пешкән гөмбә, 300 грамм үсемлек мае, 2 аш кашыгын өеп тоз, 200 грамм (8 аш кашыгы түбәләмә) шикәр комы, 100 миллилитр (6 аш кашыгы+2 чәй кашыгы) 9 процентлы серкә, дәфнә яфрагы, түгәрәк борыч, хуш исле борыч, канәфер (тәмләткечләр, кем ничек ярата, шул күләмдә салына).

Суган һәм кишерне озынча итеп турап, майда җиңелчә генә кыздырып алабыз. Кәстрүлгә бушатабыз. Шуңа ваклап туралган кәбестә һәм помидор өстибез. Май, тоз, шикәр комы салып, салмак кына утта 25–30 минут пешереп алабыз. Шуннан соң пешкән гөмбә өстибез һәм, барысын бергә болгатып, әзер булганчы пешерәбез. Уттан алырга 15 минут кала, серкә, дәфнә яфрагы, борыч, канәфер салып, тагын 15 минут пешереп алабыз.

Хуш исле кайнар солянканы парландырылган банкаларга тутырабыз һәм тимер капкач белән борып ябабыз. Астын өскә әйләндереп, җылы әйбер белән каплыйбыз да, суынгач, салкынча урынга алып куябыз.

Белеп тор!

ТЕШ ЩЕТКАСЫ ХИКМӘТЕ

Йомшарып калган иске теш щеткасын чүплек савытына ыргытырга ашыкмагыз: кирәге чыгарга мөмкин.

✓Щетканың йомшак кыллары теләсә кайсы тараны чистарту өчен бик уңайлы.

✓Бакчада эшләгәннән соң шуның белән тырнак астын чистартырга була.

✓Җылыткыч батареяны буяганда, пумала белән кереп булмый торган өлешләрен щетка белән буярга мөмкин. Моның өчен тоткасын кайнап торган суга салып, үзегезгә ничек кирәк, шулай бөгәргә була.

Матурлык сере

ШОКОЛАД ТӨСЕН САКЛА!

Ял итүчеләр өчен «бәрхет сезоны» дәвам итә. Көньяк тарафлардан бик матур төскә кереп, кызынып кайту гына да ни тора! Ләкин тән тиресе шоколад төсен бик озак саклый алмый шул. Әмма серләрен белсәң, матурлыкны дәвамлырак та итәргә мөмкин.

➤Ялдан соң мунчада озак парланып утырмаска тырышыгыз, юкса тән тиресендәге су бик күп микъдарда парга әйләнәчәк. Бу исә тиренең тизрәк агаруына китерә.

➤Ә менә төрле эфир майлары һәм диңгез тозы салынган ваннада юыну шоколад төсен тәнгә ныграк сеңдерү мөмкинлеге бирә.

➤Иртән битне сыек кына кара чәй белән юып алу әйбәт. Ул тән тиресенең матур төсен саклап калу белән бергә, аны дымландырачак һәм ялкынсынуны да булдырмаячак.

➤Тирене агартучы косметикадан баш тартыгыз. Составында лимон, сөт, каклы үлән (чистотел), кыяр булган маскалар сөртмәгез. Тукланута да игътибар итегез. Мәсәлән, зәйтүн мае, майлы балык тән тиресенең коңгырт төсен сакларга ярдәм итә торган тирозин матдәсенә бай. Шул ук вакытта көненә кимендә 1,5 литр чиста су эчәргә онытмагыз.

ХӨРМӘТ, ИГЪТИБАР КӨТӘЛӘР

Картлык көттереп тормас, һәркемнең ишеген шакыр. Октябрь башында гомер көзенә кергәннәрнең – Өлкәннәр көнен билгеләп үтәбез. Ислам динендә өлкәннәрне хөрмәтләү – бик әһәмиятле төшенчә, бу иманның һәм Аллаһыны олылауның бер күрсәткече санала.

Өлкәннәргә карата рәхим-шәфкатьле булу, аларны олылау турында Алмаз хәзрәт ГАЛИМҖАНОВ белән сөйләштек.

:: Динебездә өлкәннәргә хөрмәт турында ни диелә?

– Ислам дине өлкәннәргә яхшы мөнәсәбәттә булуны таләп итә. Гомумән, без һәр кешегә карата хөрмәт күрсәтергә тиеш. Әмма Аллаһы Тәгалә өлкәннәргә аеруча мәрхәмәтле булырга куша. Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисендә: «Минем өммәтемнең яше – 60 белән 70 арасы. Бу яшьтән артканның һәрбер елы – Аллаһның рәхмәте», – диелә. Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.) үзе дә өлкәннәргә карата бик яхшы мөнәсәбәттә булган. Шундый вакыйга да билгеле: яһүди кавеменнән булган сукыр берәү базарга чыгып, пәйгамбәребезне (с.г.в.) «ул начар, ул юньсез» дип сүгә торган була. Пәйгамбәребез (с.г.в.) моны ишетеп, көн дә аны ашатырга йөргән. Ул вафат булгач, аның сөннәтен дәвам итү максатыннан, иң якын сәхабәләренең берсе бу яһүдине ашата торган була. Бу сукыр, ризасызлык белдереп: «Син кем?» – дип сорый. Сәхабә: «Мин – сине ашатучы кеше», – ди икән. Яһүди исә: «Юк, мине ашаткан кеше ризыкны башта йомшарта торган иде. Аннан гел хуш ис аңкый иде», – дигән. Сәхабә, елап, пәйгамбәребез (с.г.в.) инде бу дөньяда юк, ди. Теге карт сискәнеп китә. «Мин бит аны көн дә сүгә идем, ә ул мине ашатып йөргәнме?» – ди дә ислам диненә күчә.

Аллаһның илчесе: «Берәр кеше олы кешегә хөрмәт күрсәтсә, Аллаһы Тәгалә олыгайган көнендә аңа да хөрмәт күрсәтер кешене янына китерер», – ди.

:: Хәзер яшь гаиләләр бала тәрбиясендә әби-бабайны бик катнаштырмый. Үсеп килүче буынны тәрбияләүдә аларның роле нинди?

– Әби-бабайда бала тәрбияләү тәҗрибәсе бар. Алар да бу эштә катнашса, хәерле. Безгә дә бит догалар, Коръән аятьләре гыйлемле әби-бабаларыбыз аша күчкән. Хәзер 1960–1980 нче елларда туган кешеләр – үзләре әби-бабай. Әмма 1930 нчы елларда туган әби-бабайларыбыз белән чагыштырганда, аларның оныкларына бирерлек дини гыйлеме азрак. Балаларга рухи мирасны тапшыру – безнең өстебездәге бурыч. Әби-бабайлар дини белемне генә түгел, башка тормыш дәресләрен дә яхшы бирә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Өлкәннәр белән сөйләшкәндә нинди әхлак кагыйдәләрен истә тотарга?

– Ислам дине синнән яшь, гыйлем дәрәҗәсе, дөньяви дәрәҗәсе ягыннан аерылып торган кеше белән әдәпле, әхлаклы булып сөйләшергә куша. Гомумән, әдәпле сөйләшү синең телеңә зыян китерми. Киресенчә, Аллаһы Тәгалә каршында зур абруй яуларга булыша.

:: Олыгайган көннәрендә ата-анасын җиде ятка калдыручылар да, картлар йортына илтеп тапшыручылар да шактый...

– Бу – кызганыч күренеш. Ислам динендә: «Олы яшькә җиткән ата-анаңны кайгырту, яшәешен тәэмин итү – бурычың», – диелгән. Әмма кайбер вакытта гаеп ата-анада да була. Мәсәлән, үзләре дә олы яшькә җиткән ата-анасына җәбер күрсәткән булулары ихтимал. Аллаһы Тәгалә: «Ни күрсәтсәң, шуны күрерсең», – ди. Барысы да кире кайта.

:: Өлкәннәребезгә олыгайган көннәрендә дә күңел көрлеге югалтмас өчен нишләргә?

– Өлкән яшьтәгеләргә шуны әйтәсе килә: бу дөньяда без – барыбыз да кунак. Җәннәттә барыбыз да 33 яшьтә булырбыз, диелә. Олыгайган көндә догалар укып, игелекләр кылырга, Коръән укырга, намазга басарга кирәк. «Мин карт, минннән булмый», – димик. Буш вакытны гыйбадәткә, оныклар тәрбиясенә багышласак хәерле. Бер оныкны булса да дога кылырга өйрәтсәк, ничек хәерле! Өйдә утырабыз дип, актив тормыштан артта калырга кирәкми.

Октябрь аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Якш	03:40	05:45	15:19	17:20	19:01
2	Дүш	03:42	05:47	15:17	17:17	18:59
3	Сиш	03:44	05:49	15:15	17:15	18:56
4	Чәрш	03:47	05:51	15:12	17:12	18:53
5	Пәнҗ	03:49	05:53	15:10	17:09	18:51
6	Җом	03:51	05:55	15:08	17:07	18:48
7	Шим	03:53	05:57	15:06	17:04	18:45
8	Якш	03:55	05:59	15:03	17:02	18:43
9	Дүш	03:57	06:01	15:01	16:59	18:40
10	Сиш	03:59	06:03	14:59	16:57	18:38
11	Чәрш	04:01	06:05	14:56	16:54	18:35
12	Пәнҗ	04:03	06:07	14:54	16:52	18:33
13	Җом	04:06	06:09	14:52	16:49	18:30
14	Шим	04:08	06:11	14:50	16:47	18:28
15	Якш	04:10	06:13	14:47	16:44	18:25
16	Дүш	04:12	06:15	14:45	16:42	18:23
17	Сиш	04:14	06:17	14:43	16:39	18:20
18	Чәрш	04:16	06:19	14:41	16:37	18:18
19	Пәнҗ	04:18	06:21	14:39	16:34	18:16
20	Җом	04:20	06:23	14:36	16:32	18:14
21	Шим	04:21	06:25	14:34	16:29	18:11
22	Якш	04:23	06:27	14:32	16:27	18:09
23	Дүш	04:25	06:29	14:30	16:25	18:07
24	Сиш	04:27	06:31	14:28	16:22	18:05
25	Чәрш	04:29	06:33	14:26	16:20	18:03
26	Пәнҗ	04:31	06:35	14:23	16:18	18:00
27	Җом	04:33	06:38	14:21	16:15	17:58
28	Шим	04:35	06:40	14:19	16:13	17:56
29	Якш	04:37	06:42	14:17	16:11	17:54
30	Дүш	04:39	06:44	14:15	16:09	17:52
31	Сиш	04:40	06:46	14:13	16:06	17:50

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Йәгез, бер дога!

ҺӘРВАКЫТ ҺӘМ ҺӘР УРЫНДА УКЫРГА МӨМКИН

«Әлхәмдүлилләәһи галәә күлли хәәлин фәиннәһү мүхәввилүлхәвәәл. Раббәнәә әәтинәә фиддүнйәә хәсәнәтән вә фил-әәхырати хәсәнәтән вә кыйнәә гаҙәәбән-нәәр. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин».

Мәгънәсе: «Һәр хәл өчен Аллаһы Тәгаләне мактыйбыз, чөнки хәлләрне үзгәртүче – Ул. Йә, Раббым, безгә дөньяда да, Ахирәттә дә изге хәлләрне насыйп ит. Шулай ук безне җәһәннәм газабыннан сакла, әй, Рәхмәтле Аллаһы, бөтен нәрсә Синең рәхмәтеңдә».

Хикмәтле сүз

«Әгәр үлемнән яки үтерелүдән качсагыз [әҗәлегез җиткән булса], бу качу сезгә файда китермәячәк».

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:16

«Ашагыз, эчегез, әмма [хәләлне харам итеп, яки харамга катышып, яки туклык чиген узып] исраф итмәгез. Һичшиксез, Ул [Раббыгыз] исрафчы кешеләрне сөйми», – дип әйтелгән.

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:31

«Хаҗ кылырга ашыгыгыз, чөнки берегез дә үзенә әҗәл кайчан ирешәсен белми».

(Хәдис)

«Һичшиксез, синең Раббың теләгән кешегә [кайчак] ризыкны мул итәр һәм тарайтыр. Һичшиксез, Ул – колларыннан хәбәрдар һәм күрүче».

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:30

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Мин = милләт

Асыл

МАРИЯ АРУТЮНЯН, ӘРМӘН, 20 ЯШЬ

Милли асыл дигәндә күз уңында үзеңне җәмгыятьтә күрсәтү генә түгел, синең теге яки бу милләткә катнашың барлыгын тою да торадыр, дип уйлыйм. Моның өчен миңа, әлбәттә, **ТУГАН ТЕЛЕМДӘ СӨЙЛӘШҮ, ВАТАНДАШЛАРЫМ БЕЛӘН АРАЛАШУ, ВАТАНЫМА КАЙТУ** булыша. Ә җәмгыятьтә мин әрмән булуымны **ИҖАТ АША** күрсәтәм. Әрмән биюләре һәм җырлары белән концертларда һәм төрле конкурсларда катнашам.

Без Казанда 14 ел яшибез. Бирегә күченүгә, әлбәттә, йолаларны, традицияләрне саклау, үтәү кыенлашты. Әмма Татарстанда моның өчен **БАРЛЫК ШАРТЛАР ДА ТУДЫРЫЛА.** Безне әни Казанга күченеп килүебезнең беренче көннәрендә үк Халыклар дуслыгы йортындагы якшәмбе мәктәбенә бирде. Бу безгә **МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕБЕЗНЕ, ЙОЛАЛАРНЫ, ТЕЛНЕ ОНЫТМАСКА** нык булышты. Өйдән тыш та үз телебездә сөйләшергә мохит булды ул.

ТЕЛ УЛ – ХАЛЫКНЫҢ ТРАДИЦИЯЛӘРЕН ҺӘМ ХАЛЫКТА БУЛГАН БЕЛЕМНЕ ТАПШЫРУ ЧАРАСЫ, КИЛӘЧӘК БЕЛӘН ҮТКӘН АРАСЫНДАГЫ КҮПЕР. Һәр тел үзенчәлекле. Аны саклау – милләтне саклау дигән сүз.

Бала тәрбиясендә милли традицияләрне, телне куллану һәм үсеп килүче буынга тапшыру – төп бурычларның берсе. Минемчә, иң мөһиме – үз телеңдә **АРАЛАШУ**, яшьтән үк милли ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ сеңдерү кирәк. Тарихи ватанга кайту да үзенекен итә.

Җир шарындагы һәр кешенең үз милләте белән горурланырга хокукы бар. Әрмән булу – **МЕҢЬЕЛЛЫК ТАРИХЫ БУЛГАН МИЛЛӘТНЕҢ БЕР ВӘКИЛЕ** булу дигән сүз. Искиткеч табигате, матур пейзажлары, бик күп истәлекле урыннары, тәмле ризыклары – минем ватанымны таныткан кайбер нәрсәләр генә әле бу. Безгә **КУНАКЧЫЛЛЫК, ДУСЛАРЧА МӨНӘСӘБӘТ, ТУГАН ҖАНЛЫЛЫК, ӨЛКӘННӘРГӘ ҺӘМ ГАИЛӘ КОРУ ТРАДИЦИЯЛӘРЕНӘ ИХТИРАМ БЕЛӘН КАРАУ ХАС**. Мин әрмән булуым белән горурланам!

Аның сөйләшүеннән үк үз милләтенә булган хөрмәте һәм мәхәббәте сизелә. Мария – актив кыз. Хәзерге вакытта Халыкара туризм академиясенең Казан филиалында белем ала. Моннан тыш, эшләргә дә, иҗатка да вакыт таба.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Фото: Анна АРАХАМИЯ

4 октябрь | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
Килешәсездер: авыл белән гомер буе шәһәрдән торып идарә иттеләр һәм итәләр. Гаепләсәң – гаеп, көлсәң – көлке булырлык хәл. Кайчан басуга чыгасын да, ни чәчәсен-утыртасын да өйрәтәләр, нишләтеп чәчәсен һәм утыртасын, кайчан агулыйсын, кайчан уракка төшәсен (әйтерсең, кайсы басуы өлгергәнен авылдагылар күрми һәм аермый)… һәм башкасын, һәм башкасын… Аңлыйм, теорияне шәп белүче белгечләр күп. Тик авыл тормышы китапта язылганча гына бармый, теория белән генә ерак китеп булмый. Җирнең, авылның үз законнары, үз кагыйдәләре аның.

Яшәешебезнең 70–80 проценты табигатькә бәйле ләбаса. Аның исә – үз «технология»се, үз фәлсәфәсе. Ә авыл кешесе җиргә якынрак, ул үз җиренең холкын да, сәләтен дә, табигатен дә инде өйрәнеп бетергән. Өстән бармак төртмәсәләр дә, ул анда кайчан нишләргә кирәген белә. Тик өстәгеләр кебек үк, ул да Табигать каршында көчсез.

2010 елгы юклыктан гаҗизләнгәндә, күп терлек асраган бер хуҗалык җитәкчесе: «Булганны җыеп алырга була икән. Яңгырлар яуса да, хәзер техникалар куәтле, киптерү җайланмалары бар», – дигән иде. Ә берничә елдан ук яңгырлар тоташ койды һәм ул җәй болай да эшләп булмаганны күрсәтте. Авыл хуҗалыгы бик катлаулы, анда бүген әйткән фикерең дә иртәгә ярамаска мөмкин. Елына карап, эшләү түгел, кырга чыга, басуга керә алмый бәргәләнгән көннәре дә күп була игенченең.

Кыскасы, алай да вай, болай да вай. Тик алтын урталык дигәннәре – без теләгән уңай шартлар ел да булмый шул. Кояш көтеп тилмергән чаклар да, быелгы кебек, яңгыр көткән чаклар да безнеке – сала кешеләренеке. Түзә, әмәлен таба, барыбер эшли ул аны. Зарланулары да болай гына, сүз иярә сүз чыгып кына...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ҖЕН КҮЗДӘН ЧЫКСА, КЕШЕ СУКЫРАЕРГА МӨМКИН

Күз тию, сихер турында еш ишетергә туры килә. Кешегә җен ияләшсә, тагын да хәтәррәк. Безнең авылда яшьли тол калган бер хатын: «Ярты еллап яныма кемдер килә, кочарга тели, тәннәремне күгәртеп бетерә. Үзе күренми дә», – дип зарланган иде. Дин әһелләре моны, җенпәри галәмәте, ди. Җеннәр ни сәбәпле ияләшә? Алардан ничек сакланырга?



Бу хакта Салмачы бистәсенең «Хәдичә» мәчете имам-хатыйбы Фәрит хәзрәт КАДЫЙРОВ белән сөйләштек.

vk.com

Җеннәр кешегә яратып та керә

:: Фәрит хәзрәт, җен кешегә нигә керә?
– Бу дөньяда Аллаһы Тәгалә җеннәрне – уттан, фәрештәләрне нурдан яраткан. Коръәннең «Зарият» сүрәсе 56 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә: «Кеше белән җеннәрне фәкать Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен халык кылдым», – диелә. Җеннәр арасында төрлесе бар. Кайсы намаз укый, Аллаһы юлында. Кайсы кешегә начарлык кыла. Җеннең кешегә керү сәбәпләре күп төрле. Кайсы яратып керә, кайсы үч алырга тели. Чибәр кешеләргә күпләр сокланып карый, җеннәр исә, шуннан көнләшеп, матурлыгын бетерер өчен явызлык кылырга мөмкин. Кайчакта туганда ук балаларга җен тигән була. Мондыйлар хакында «нәселенә җен кагылган» диләр. Бу очракта күпме өшкерсәң дә, кешедән җенне чыгару авыр. Җеннәр эт, мәче, кеше кыяфәтендә дә килергә мөмкин. Үземнең дә алар белән сөйләшкәнем булды. «Нигә бу кешегә кердең?» – дип сорагач, төрлесен сөйлиләр: кайсы – фатирым юк, кайсы гашыйк булдым, ди. Җеңгә ышанырга ярамый. Алар еш кына алдыйлар.

:: Кешегә җен кергәнне тоеп буламы?
– Мондый вакытта кеше хәлсезләнә, күзендә нур югала, сәбәпсез авырыйга, күңел төшенкелегенә бирелергә мөмкин. Эче поша. Кайчак сәбәпсез елый. Кәефе еш үзгәрә. Коръән сүрәләрен тыныч кына тыңлый алмый. Үзенә урын тапмый. Азан тавышы ачуын чыгара.

Зират өстенә йорт салмагыз

:: Йортка да җен керергә мөмкинме?
– Җеннәрне без күрмибез. Алар арабызда. «Бисмилла» әйтми урындыкка утырсак, анда да җен баласы булуы бар. Бервакыт мине берәү йортына чакырды. «Күземә чит кешеләр күренә, аягыма төртеп үтәләр, өемне туздыралар, өстемә су сибәләр, әйберләрне тотып аталар», – дип зарланды бу апа. Барып керсәк, чынлап та, өйнең асты өскә килгән. Миңа да берсе сугарга өлгерде. Шул чак эшнең нидә икәнен аңлап алдым. Җеннәр бар икән анда. Азан әйтеп, ясин укыгач, өч кенә көн тыныч торганнар да тагын шаулаша башлаганнар. Бу юлы өйнең дүрт чатына азан әйтеп, мылтыктан аттык. Шуннан соң тындылар. Берсендә зират өстендә салынган йортта тыныч түгел дип чакырганнар иде. Бу юлы мылтыктан ату да булышмады. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Кабер өстенә басканчы, утлы күмергә басуың хәерлерәк», – дигән. Зират булган урынга йорт салмаска тырышырга кирәк.

:: Кешедән җен чыгарганда нинди догалар укыйсыз?
– Коръәннән аятьләр укыйм. Җеннәрне усаллык белән җиңеп булмый, сак кыланырга кирәк. Җен күздән чыкса, кеше сукыраерга, колактан чыкса, саңгырауланырга мөмкин. Авыздан, аяк-кулдан чыкса хәерлерәк. Һәр дога шифалы. Күз тию, сихер чыгарганда, җенпәриләрдән котылу өчен «Аятел Көрси», «Әгъраф», «Саффат», «Та-һа», «Бәкара», «Ихлас», «Фәләкъ», «Нәс» сүрәләрен укып өшкерәм. Җен кергән, күз тигән кеше өшкергәндә йә елый, йә көлә, кайберләре кычкыра.

«Бисмилла» әйтеп йөр

:: Күз тиюләрдән түгәрәк ясин белән дә өшкерәләр, дип ишеткәнем бар.
– Зур гына тукыманың, йә катырак кәгазьнең уртасын кеше башы сыярлык итеп кисәләр дә, калган өлешенә ясинне язып чыгалар. Шул түгәрәк ясинне кешенең башыннан кидереп, аягыннан чыгаралар. Шул рәвешле күз тиюләр бетә дип санала. Тик бу өшкерү ысулы шәригать кануннарына туры килми. Диндә ясин белән башкача дәвала违алар. Каләмне зәгьфран үләне суына манып, ясинне гарәп хәрефләре белән тәлинкәгә кулдан язалар. Шул дога язылган тәлинкәне чайкаган суны эчәләр.

:: Күз тиюдән, җеннәрдән ничек сакланырга?
– Чынлыкта, күз тиюдән бары Аллаһы гына саклый. Һәрчакта да «бисмилла» әйтеп йөрергә кирәк. Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә: «Өеннән «бисмилла» әйтеп чыгып киткән кешене 70 мең фәрештә саклап йөрер», – диелә. Җеннәр күбрәк нәҗес урыннарда: бәдрәфтә, мунчада, башка пычрак җирләрдә яши. Шуңа да хаҗәтеңне үтәгәч, бәдрәфтә озак утырмаска, мунчага тамак кырып керергә киңәш ителә. Фото аша бозу да очрый. Шуңа да социаль челтәрләргә фотолар куйганда саграк булырга кирәк. Кабер туфрагы белән сихер кертүчеләр бар. Бозымнардан саклану өчен намаз укырга, Аллаһы кушканча яшәргә, зикерләр әйтергә, тәһарәтле, госелле йөрергә тырышыгыз. Гаурәтләрне каплап йөрү дә күз тиюдән саклый. Сихер чыгарам дип, алдакчы күрәзәчеләр, шарлатаннар корбаны булырга язмасын. Андыйлар хәзер күп. Күбесе космостан көч алам, энергия белән дәвалыйм, дигән була. Әмма алар шайтан белән элемтәдә. Дәваны бирүче – бер Аллаһы.

Наил ЯРУЛЛИН

Шушы доганы иртәнге һәм ахшам намазыннан соң 100әр тапкыр кабатласаң, кешегә сихер, җен кагыла алмас.
«Ләә иләәһә илләллаһү вәхдәһү лә шәрикә ләһ. Ләһүл-мүлкү вә ләһүл хәмдү вә һүә галә кулли шәйин кадиир».
Мәгънәсе: «Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы бернинди зат юк, бер Раббыбызга гына гыйбадәт кылырга тиешбез, Аның тиңдәше юк. Бөтен патшалык Аның кулында, барча мактау Аллаһы Тәгаләгә генә хастыр. Раббыбыз бөтен нәрсәгә кодрәтледер, бөтен нәрсәгә көче җитә».

Эчтән соклансаң да күз тия

Апас районы Аккуҗа авылыннан Гөлирам Нигъмәтҗанованы ул якларда белмәгән кеше юк. Йортын эзләгәндә адашып, күрше авылга кергәч тә, урамда уйнап йөрүче балалар Гөлирам әбинең кайда яшәвен җентекләп аңлаттылар безгә. Аның әбисе, әнисе дә атаклы өшкерүчеләр булган. Гөлирам апаларга килергә теләсәң, алдан шалтыратырга кирәк. Чөнки еш кына аны башка авылга да алып китәләр. Әйтүенчә, өшкерү сәләте аңа әнисеннән күчкән.
– Әнине якын-тирә районнарда «Барыш тәтә» буларак беләләр иде, янынан кеше өзелмәде. Догаларны да аннан өйрәндем. Әнием 96 яшенә җитеп вафат булды. Аңа йөрүчеләр миңа килә башлады. Кешене кире борырга уңайсыз. Белгәннәремне укып өшкерәм. Аллаһының рәхмәте, файдасын күрәләр, – ди 81 яшьлек Гөлирам апа.
Аңа кемнәр генә мөрәҗәгать итми. Кайсын борынына чыккан сөял борчый, кайсының күзе эренләгән, кемдер төнлә йоклый алмый, экчечелектән интегүчеләр дә җитәрлек. Соңгы елларда бозымнан, күз тиюдән газапланып килүчеләр аеруча арткан.
– Кызганыч, кеше хәзер гөнаһтан курыкмый. Көнләшә, нәфескә хуҗа була белми. Якыннар, туганнар арасында да көнчелек күзәтелә, – ди өшкерүче әби.
Кешегә күз тигәнне ул өшкерә башлауга тоя. Тәсбихен тарта-тарта догалар укып өшкерә, бетчә, тимрәү кебек нәрсәләр чыкканда шифалы су да ясап бирә. Үзең белән алып килгән ризыкларны да өшкерә. «Кайбер кешенең күзе, теле белән әйтмәсә дә, эчтән генә сокланса да тияргә мөмкин», – ди. Шуңа да һәрчак догалар укып, «бисмилла» әйтеп йөрергә киңәш итә ул.

ГӨЛСАРА ӘХМӘТОВА:

«КЫЗЫМНЫҢ ДҮРТ БҮЛӘГЕ»

Казанда яшәүче Гөлсара Әхмәтова бик күп авырлыклар кичергән. Язмыш аны ничек кенә сынаса да, сер бирмәгән үзе. Сугып еккан чакларында да торып басар көч тапкан. Башта, балаларым, дисә, хәзер, оныкларым, дип яши. 68 яшьлек Гөлсара апа дүрт оныкны берүзе үстерә.

Гөлсара Әхмәтованың шәхси архивыннан

– Әтнә районының Күшәр авылында туып-үстем мин. Әтиебез белән әниебез икесе дә сөйләшмиләр иде, – дип сөйли Гөлсара апа. – Алты бала кечкенәдән бер-беребезгә терәк булдык. Әти-әнидән матур сүзләр ишетеп булмаса да, алар үзләренчә ярата белде. Телләре булмаса да, бар эшкә, тәртипкә өйрәтеп үстерделәр.

Гөлсара апа 19 яшендә Кече Әтнә авылы егете Шамилгә кияүгә чыга. Башта кызлары Гөлнара, аннан соң Альмира туа. Берничә ел авылда яшәгәннән соң, гаилә Казанга күченә. Бик матур яшиләр. Гөлсара апа ирен хөрмәт итеп тора, ул да хатыны өчен өзелеп яши. Тик Шамил абый кыска гомерле була: 43 яшендә кинәт кенә үлеп китә. Нибары 25 ел бергә яшәп кала алар.

Тормыш дәвам итә, бер-бер артлы кызлары гаиләле була. Иң элек Гөлнара кияүгә чыга.

– Башта балалар бездә тордылар. Аннары авылга күчәргә уйладылар. Әмма соңрак барыбер шәһәрне сайладылар. Уллары туды. Аңа өч яшь чагында киявебез суга батып үлде. 25 яшь кенә иде әле үзенә. Гаиләбезгә килгән бик авыр сынау булды ул. Баламны юатыр сүзләр таба алмый идем кайчак. Киявебез бик тырыш иде. Ул үлгәч, тормыш көтү кызым җилкәсенә күчте. Гөлнара базарга эшкә урнашты. Балык сатты. Шунда бер ир белән танышып, никах укыттылар. Матур гына яшәделәр. Бер-бер артлы өч балалары булды, – ди Гөлсара апа. – Кызым өйдә озак утырмады, эшенә чыкты. Беләсез инде, сату эше җиңел түгел. Кызым төнлә товарга чыгып китәр иде. Кая анда юньләп ял итү?! Бервакыт яныма килеп: «Әни, минем хәлем китә, йөрәгем дә каты тибә», – диде. Табиб чакырттык. Ике мәртәбә тынычландыра торган укол ясап киттеләр. Өченчесе хастаханәгә барырга кушты. Андагы табиблар чирне тиз тапты: баламда кан рагы булган икән. Инде өченче стадиягә җиткән.

Авыр көннәр башлана. Өйдә дүрт бала, Гөлнараның хәле начар. Шунда да Гөлсара апа үзендә көч таба. Ничек итсә итә, баласын юатырга тырыша. Көндезләрен Гөлнара янына хастаханәгә әнисе бара, төнгә ире килә. Ничек кенә дәваласалар да, алга китеш күренми. Аптырагач, Гөлнараны РКБга күчерәләр. Химия терапиясе үткәрәләр. Тик нәтиҗәсе булмый: организмы андый дәваны кабул итми. Хәлен җиңеләйтүче уколлар белән генә яши башлый ул. Шунда күңеле сизенә: «Әни, мин үлемемне көтеп ятам инде», – ди. 43 яшендә җомга иртәсендә китеп бара ул. Ходай аңа да әтисенеке кадәр генә гомер биргән булып чыга.

Бу вакыйгадан соң 6 ел узып киткән инде. Гөлнараның балалары Гөлсара апа белән кала.

– Аларга опекун булдым. Беренче никахыннан туган улы Илдус та янымда. Энеләре һәм сеңлесен ташламый. Рәмис улыма да 17 яшь инде, Ралинә кызыма 15 тулды. Алар әниләренең вафатын аңлап кабул иттеләр. Ә кечесе Рамилгә әнисенең кайтып булмый торган җиргә киткәнен әле быел гына әйттек. Аңа да 13 тулды инде. Анысы мине бигрәк сагынып тора. Кибеткә дә чыгып керер хәл юк. «Син кайда?» – дип шалтырата башлый, – ди Гөлсара апа. – Альмира кызымның өч кызы бар. Алар да Казанда яши. Авырлыкларны бергә күтәрәбез. Апасының балалары өчен өзелеп тора ул да. Шөкер, авыр яшәмибез. Бар нәрсәбез бар. Пенсия алам, хөкүмәт балаларга акчасын биреп тора. Зарлана алмыйм. Хәйрия фондлары онытып бетерми. Быелга кадәр мәктәп кирәк-яраклары да бирделәр. Аларга рәхмәттән башка сүзем юк.

Язмыш Гөлсара апага сынауларны шактый бирә әле. Бирешмәскә тырышса да, борчу-хәсрәт эзсез югалмый. Гөлсара апада табиблар шикәр авыруы таба. Хәзер дарулар эчеп кенә тора икән.

– Нинди генә сынау килсә дә, сабыр итәргә тырыштым. Һәр авырлыкны күтәрә алган саен, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт укыдым, тормышыма шөкер иттем. Шушы яшемә кадәр яши алуыма сөенәм. Елап нишли алам соң? Яшәргә кирәк, – ди ул. – Бар теләгем шул: ничек тә авырмыйча, шушы балаларымны аякка бастырасы иде. Алар бик акыллы. Тырышып укыйлар. Әниләре сөенеп ятадыр...

Йосыповаларның гаилә архивыннан

ЯШӘТЕРГӘ ИДЕ

Зәй районының Кушъелга авылында гомер итүче 44 яшьлек Гөлнара Йосыповага ярдәм кирәк. Түбән Биш авылының балалар бакчасында пешекче, Кушъелга авылында хат таратучы булып эшләүче Гөлнараның бер елга якын нинди авырудан интеккәнен ачыклый алмыйлар.

Туганнары чаң суга – якын кешеләрен ничек тә яшәтәсе иде. Гөлнараның өч баласы әнисенең савыгуын көтә. Олы баласына – 23, иң кечесенә 10 гына яшь әле. Әнә шул нәние, әнине яшәтәсем килә, дип өзгәләнә.

– Сеңлем быелның гыйнвар аенда, кар көрәгәндә авырып киткән. Башта биле сызлый. Берничә ай узса да, авыруы чигенми, киресенчә, көчәеп, инде аякларына да төшә. Көч-хәл белән йөри башлагач кына, түләүле клиникага барып, табибларга күренде. Алар дарулар язып биргәч, хәле яхшырып киткәндәй булды. Барыбыз да сөенеп куйган идек. Әмма озак та тормады, Гөлнараның кан басымы күтәрелә башлады, – дип сөйли апасы Венера. – Кая гына йөртмәдек. Калкансыман бизен дә тикшерттек, лимфа төеннәре зурайган иде.

Гөлнараны онкологка җибәрәләр. Әлмәт, Зәй, Чаллы, Казан табиблары барысы да бер нәтиҗәгә килә: яман чир юк. Төгәл диагнозны ачыклар өчен биопсия анализын Санкт-Петербургка да җибәреп карыйлар. Алардан да яман чир юк дигән хәбәр килә. Әмма организмында ниндидер инфекция барлыгын ачыклыйлар. Лимфа төеннәренә операция ясыйлар.

– Гөлнараны РКБга салдылар. Анда дәваланды. Әмма алга китеш булмады. Аптырадык инде. Йөрәк әрнеде. Туганымның күзгә күренеп хәле начарлана. Чирен төгәл әйтүче булмады. МКДЦга да мөрәҗәгать итеп карадык. Алар сеңлемнең арка миенә зыян килүен ачыкладылар. Авыру неврологиягә бәйле. Полинейропатия диләр. Красная волчанка яки амилоидоз дигән диагнозы да булырга мөмкин, ди табиблар, – ди Венера. – Төгәл диагноз куелмагач, Гөлнарага инвалидлык та бирмиләр. Хәтта документлары да әзерләнмәгән әле. Арка миенә килгән зыянны бары тик кыйммәтле дарулар белән генә дәвалап була икән. Әле менә шушы көннәрдә 10 мең сумлык анализ бирдек. Ничек тә дөрес дәва аласы килә. Әлегә без хастаханәдә ятабыз. Онкологлар яңадан җыелышып, сеңлемнең авырулары турында сөйләшәчәк. Лимфа төеннәрен кабат тикшермәкчеләр. Бер авыру икенчесенә комачаулый, диләр. Нишләргә дә белгән юк. Кайбер табиблар коронавирусның бер төре дә булырга мөмкин, диләр. Билгесезлек бик авыр.

Әлегә Гөлнараның диагнозлары ачыкланып бетмәсә дә, табиблар иммунитетны күтәрә торган дәвалау кирәк, диләр. Ә ул бик кыйммәт икән. Арка миенә килгән зыян организмның башка өлешенә дә йогынты ясамасын өчен дарулар эчәргә кушканнар. Анысы өчен дә акча кирәк.

Гөлнарага ярдәм итүебезне Кушъелга авылында яшәүчеләр сорады. Алар үзләре 380 мең сум акча җыйган инде. Тагын 700 мең сум акча кирәк, диләр. Шуңа да алар мәрхәмәтле кешеләрдән булышуларын сорый.

Ярдәм итәргә теләүчеләр өчен: Гөлнара Заһир кызы Йосыпованың 89274920564 телефон номеры Саклык банкы картасына беркетелгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

АЛЬФРЕД ЯКШИМБЕТОВ:

«ҖЫР ЯЗГАНДА, ХАТЫНГА ЧЫГЫП ТОРЫРГА ТУРЫ КИЛӘ»

Гармунчы абруе, татар эстрадасы хәле, авторлык хокуклары, җыр хакы, гаилә, тәрбия. Татарстанның һәм Башкортстанның атказанган артисты Альфред ЯКШИМБЕТОВ белән әнә шул темаларга сөйләштек. Иҗат кешесенең гаиләсе нинди булырга тиеш, популярлыкның асылы нәрсәдә дигән сорауларга җавап таптык шикелле.

:: Альфред абый, баянлы стажыгыз күпме?

– Бишенче сыйныфта укыганда кулга беренче тапкыр баян алдым. Шул елдан параллель рәвештә Уфада музыка мәктәп-интернатында да укый башладым. 1972 ел иде ул. Аңа чаклы баянны кулга алган булмады. Минем әти – тракторчы, гомере буе колхоз алдынгысы булды. Алдынгы буларак Мәскәүдә булып кайтты. Әти интернат турында белдерү күргән дә мине дә шунда укытырга булган. Һәр ата баласының үзеннән укымышлырак булуын тели. Күрәсең, миндә музыкаль сәләт барлыгын сизгәндер. Хәер, безнең гаиләдә һәрберебез диярлек музыкаль. Бәләкәй чакта без, биш бала, әткәйләргә концерт куя идек. Шунда мин берәр китапны алам да, аны «тальян» итәм, авыз белән тавышын чыгарам. Сеңел кушылып җырлый башлый, апа эләктереп ала. Туганнарым, музыкаль белем алмасалар да, барысы да бик матур җырлый. Бу сәләт, күрәсең, буыннан-буынга күчә бара. Әйтик, икетуганнар арасында Фуат Әхмәтов Салават драма театры артисты иде. Ул хәзер мәрхүм инде, урыны оҗмахта булсын. Тагын бер икетуган сеңлем Светлана Хәкимова – Мәҗит Гафури исемендәге театрда артист. Баянлы стаж 1972дә башланды дип алсак, стаж шактый. Үзегез чутлап чыгарырсыз анда.

:: «Гармунчының буыннары саен мәхәббәт аның», – дип җырлыйлар бит әле. Бу инде – гармунчы кызлар арасында да, җәмгыятьтә дә абруйлы була дигән сүз. Хәзер дә шулаймы?

– Гармунчы абруе төшмәгәндер дип уйлыйм. Мин үзем дә бәләкәйдән оста баянчыларга гашыйк идем. Алар кебек буласы килде. Хәзер дә шулай. Гармунчы бит ул дөньяны башкачарак кабул итә, вак кына нәрсәдә дә матурлык күрә. Шул матурлыктан илһамланып көй туа…

:: Абруй ул – нәрсә дигән сүз? Яхшы фатир, яхшы машина, акча?..

– Син санап киткән әйберләр тир түгел эшләп алганда гына рәхәтлек китерә. Абруй үскәч, матди тотрыклылык барлыкка килә инде ул, килергә тиеш, һәрхәлдә. Әмма безнең буын өчен матди хәл беркайчан да беренче урында булмады. Без рәхәт итеп, задур белән эшләдек. Минем эш стажым 10 яшьтән башлана. Шуңа пенсиягә дә иртәрәк җибәрделәр. Гәрчә мин киләсе елга гына чыгарга тиеш идем әле. Эшләү кызык иде. Атка атланып силос таптату да, башкасы да кызык. Кулыңнан эш килгәч, рәхәт бит инде ул. Безне әти-әни әле мәктәпкә кергәнче үк, башта эшлисез, аннары уйныйсыз, дип өйрәтте. 5 яшьтә колхоз чөгендерен утарга алып баралар иде инде. Басуга, китмәнеңне күтәреп, 5 чакрым җәяү тәпилисе. Бусы да кызык, мавыктыргыч иде. Һәр йорт өчәр гектар чөгендер җирен эшкәртергә бүлеп ала. Мәктәпкә кергәч, форма, китап-дәфтәр алыр өчен без, балалар, әнигә бирелгән 3 гектарга өстәп, тагын 3 гектар җир ала идек. Җәйге каникул чөгендер арасында үтте. Анда җырлашып та аласың, тукмашып, елашып та аласың, күңелле иде. Эшләп үстек, Аллага шөкер. Шуңа безгә тормыш та кадерле.

:: Салават белән ничә ел эшлисез?

– Армиядән кайткач, 1981 елда танышкан идек, шуннан бирле бергә.

:: Салаватның холкы начар, диләр...

– Минем өчен ул – әйбәт кеше. Бөтен кешегә дә ярап бетеп булмый торган-

«Татар-информ»

дыр, холкының начар якларын күрергә туры килгән кешеләр дә бардыр. Аның урынында булсам, мин нишләр идем икән, дим. Бер мисал. Концерттан соң гадәттә ярты зал халык аның белән фотога төшәргә менә. Араларында каткат төшкәне, этешкәне-төртешкәне була. Мин шартлар идем, мөгаен, ул түзә әле. Минемчә, ул – дөрес кеше. Дөньяга аек акыл белән карый торган кеше.

Мин аның белән танышканчы җырына гашыйк идем. Аңардагы моң, харизма! Ул чакта моң дигәндә Илһам Шакировны һәм Фәридә апа Кудашеваны гына белә идем. Гәрчә ул вакытта да җырчылар күп иде. Әмма Салават җырлаганда гына каз тәне чыга иде. Музыка училищесында укыганда коридордан ул җырлап үтсә, баян белән акрын гына уйнап, артыннан иярәм. Нинди талант булуын ул үзе дә аңламый, бөтен кеше дә шулай җырлый дип уйлый иде. Аннары бергә эшли башладык. 1981–1982 нче елларда Салават, Хәния Фәрхи, мин һәм минем хатын (ул бии иде), концертлар куеп йөри башладык. Аннары Җәвитләр белән эшләп алдык. Минем бу җәһәттән кагыйдә шундый: командада эшлисең икән, бер-береңне аңлый белергә һәм тугры булырга кирәк.

:: Музыкант Наил Сәгъдиев бер интервьюда: «Минем язманы кулланып, концертларда башка баянчылар басып торганы бар», – дип әйткән. Мондый күренеш белән очрашканыгыз бармы?

– Баянчылар арасында гына түгел, бар җирдә дә шулай ул. Мин моны урлашу дип атыйм. Әйтик, Раяз Фасыйховның «Алмагачлары» дигән аранжировкасына минем генә дә бер егермеләп җырчының җырлаганын ишеткәнем бар. Ничек дип әйтим инде, Раяз үзе бер-ике кешегә биргәндер. Калганнар үзләштергән булып чыга. Чөнки тәртип юк. Бу җәһәттән Башкортстан филармониясен мисалга алырга була. Анда әле дә дистәдән артык бригада бар. Алар концертка чыгар алдыннан худсовет аша үтә. Бер генә тап булса да, сезнең монда хата бар, бу программагызны киләсе атнада тапшырырсыз, дип кире боралар. Монда кеше фонограммасына уйнаган булып та, җырлаган булып та кылана алмыйсың. Үзең җырлап, үзең алып баруга да юл юк. Үзе җырлап, үзе алып баручылар программаларын шоу-тамаша дип атый. Анда тамашачы сәхнәдә йөри, артист залда йөри, төтен җибәрәләр, әллә нишлиләр. Минемчә шоуның урыны – төнге клуб. Концерт сәхнәсенең максаты башка аның.

> «Безгә хит кирәк», – дип, җыр сорарга киләләр. Хит аларча тиз-тиз, даңгыр-доңгыр булырга тиеш. Ә бит талгын җырдан да шундый хит ясап була. Җыр кешенең күңеленә үтеп, актарып чыгарса гына хитка әйләнә ала. Ул аңга сеңә, кеше җырлап йөри башлый. Чөнки аның халәтенә аваздаш ул. Даңгыр-доңгыр хитмыни ул?! Машинада акырталар инде, машинаның эшләгән тавышы да ишетелми.

:: Сезнең җырларны кемнәр генә җырламый. Сатып бирәсезме?

– Бушка да бирәм, сатып та бирәм. Мәрхүмә Хәмдүнә апага (Тимергалиева. – **Ред.**) егерме бер җыр язып бирдем. Вафат буласы көнне дә очрашырга тиеш идек без. Башта, Хәмдүнә апа, җырлап карагыз әле дип, үзем тәкъдим итә идем. Ә бер очрашуда Хәмдүнә апа үзе: «Кара әле, син бит бу җыр өчен бер тиен дә алмыйсың, ә без аны җырлап акча эшләп йөрибез. Әйдә, ярты бәясен булса да түлик», – ди. Мин каршы килдем. «Ничек инде сездән акча алыйм?!» – дим. Хәмдүнә апа, әйтсә, бер генә әйтә бит ул. «Син бу гаиләдә берүзең эшлисең, балаларыңны, оныкларыңны ашатасың бар, сатып бир, алайса җырыңны алмыйм», – ди. Менә шундый кеше иде мәрхүмә.

Сатып бирүгә килгәндә, бездә авторлык хокуклары якланмый бит ул. Мин РАОларга кереп тә карадым, биреп тә карадым дигәндәй. Аннан бер тиен файда булмады. Шуннан авторлык хокукын җырчыга сату юлын сайларга мәҗбүр булдык. Сәхнәгә яңа гына аяк басканнарга арзанракка сатам. Әгәр инде ул ятим яки авыр хәлдә икән, болай да бирәм. Әмма һәр хезмәт өчен түләнергә тиеш. Дин әһелләре ачуланмасын, мин мисал итеп кенә әйтәм. Дога кылгач, барыбыз да сәдакасын бирәбез бит. Бушка бирсәң, юлың ябыла, дип дин әһеленең дә әйткәне бар. Зур хак түгелдер дип уйлыйм. Фатир өчен түләү ике җыр бәясе хәтле хәзер.

Үпкәм дә бар. Радио, телевидениедә җырның авторларын әйтергә нишләп

куркалар икән? Шуны әйтергә киткән секундлары жәл микән? Алай дисәң, тәмәке ише әйберләрне рекламаларга бер дә вакыт җәлләмиләр бит. Җыр бит ул – бала. Аның ата-анасы – авторлары бар. Менә мин хәзер «Уфтанма» дип әйтәм. Күбесе, бу – Салават абый җыры, дип әйтәчәк. Аның көй авторы Рәис Ханнанов, сүзләре халыкныкы. Җыр авторын атамау, балаң синеке түгел, дип әйтүгә тиң.

> Тормышта караңгылык болай да күп, телевизорны ачсаң да пычракка тап буласың. Инде сәхнәгә дә «бытовуха» менде. Халык яктылыкны каян алырга тиеш? Мине бу пошаманга сала. Элек җырчы үзен халыкны тәрбияләүче итеп сизә иде. Хәзер шушы бетте.

:: Балаларыгызны тәрбияләргә вакыт булдымы?

– Бик борчыган мәсьәлә бу. Элек концертлар 200әр көн була иде. Балаларны бик сирәк күрдем. Шуңа күрә хатыным эшен ташлады. Ул да эшләсә, минем күңелем тыныч булмас иде. Хәзер концертлар сирәгәйде, оныклар белән мәш киләм. Әле менә бу көннәрдә телефон белән көрәшәбез. Бездә аш бүлмәсенә телефон тотып керергә ярамый. Чөнки нәрсә ашаганнарын да аңламыйча калалар. Телефон – эш өчен бик яхшы нәрсә, әмма күп кеше аның бәйлелегенә төште. Мин аны наркотик, тәмәке, аракы кебек үк кешене чирләтә торган нәрсә дип карыйм. Шуңа балаларның телефонга утырырга вакытын калдырмаска тырышабыз. Музыка грамотасын да өйрәнәләр, спорт түгәрәкләренә дә йөриләр. Балаларга буш вакыт калдырырга ярамый.

:: Җырчыга нинди хатын кирәк?

– Безнең туйда Салават шаһит булды. Эштә дә, тормышта да бергә. Күпме беләм Наиләне, аның авызыннан бер 15 сүз ишеткәнем булдымы икән, дип әйткәне бар. Артыгын сөйләми, баш катырмый, мине аңлый, сиздерми генә ярдәм итә. Минем кеше. Хатыным – алтыным. Беренче күрүдән шуны аңладым һәм өч көн генә озаттым да өйләнештек.

Җыр бит ул бик уңайсыз вакытта языла. Күз алдыңа китер: йокылы-уяулы халәт, иртәнге сәгать өч. Күңелне ниндидер көй бимазалый. Билгеле бер тактка ыңгырашып-ыңгырашып куясың. Шуннан хатыным Наилә уянып, чирлисеңме әллә, ди. Наилә, чыгып тор әле, дим. Ул аңлап, чыгып китә. Кулга баян алып, акрын гына уйныйм, язырам. «Юк, юк...» дигән җырның көе менә шулай туды. Аннары шушы көйне Ләйлә Дәүләтовага тыңлаттым. Кушымтада «юк, юк» дигән сүз булырга тиеш, калганын үзең кара инде, дидем.

:: Үкенечегез бармы?

– Биш баладан исән-саулары өчәү калдык. Ике ир туганым мәрхүм булды. Менә шуларга игътибарны аз бирдем, ахры, дип үкенәм. Алай булыр дип кем белгән? Вакыт җитмәде... Алар исән чакта авылга сирәгрәк кайта идем, күбрәк телефоннан сөйләштек. Булдыра алганча ярдәм дә иттем шикелле. Барыбер үкендерә. Шөкер, әни исән. Тиздән 86 яшен тутыра. Исән-имин булырга, тормышка аек карап, шөкер итеп яшәргә насыйп булсын.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА

ШУНДЫЙ ИНДЕ БЕЗ...

(Бәян)

< Дәвамы. Башы 15, 22 сентябрь санында

– Сыергамы? – диде ирен читенә бармак калынлыгы тәмәке кыстырган шофер. – Әйдә, бырат!

Кабинага үрмәләп менгән Мирзам:

– Безгә ут капмасмы икән, агай? – дип шаяртты.

– Калхуз сәләмәсе, майны күп яндыра! – Агай рульне җитез бора, тәгәрмәч астыннан пыркылдаган балчык кисәкләре тәрәзә пыяласына чәчри иде. – Муртайса да, авылга хезмәт итә үзе. Икәү бергә картаябыз. Кафил, син бит пинсәдә, чебеш-тавык кына асрап, үз рәхәтебез өчен генә яшик, ди карчык. Фи, ир-ат шөгылемени ул, мәйтәм, мин сиңа әтәч мәллә, тавыклар белән тирестә тибенергә, мәйтәм.

Егет ирексездән юлдашына карап алды. Авызы зур, эче тулы сүз... Татайларда артык күп сөйләгән кеше турында: «Сүз боткасы пешерә», – диләр. Пешерә агай, пешерә...

– Мондый баткаклыкта чүт кенә ялы да комачауламас иде дә, әнә бит сайлаулар алдыннан ысмутр дигән

– Әһе, атың бүтән икән шул, – диде дөбер-дөбер кайнаган шофер, кисәк сүрелеп. – Тач Зөбәрҗәт кияве үзең! Игезәкләр диярсең, Ходайның хикмәте. Нәстә майтарырсың икән клубта, бырат?

Сәнгать җитәкчесе дисәң, агай мәгънәсенә төшенмәс, аның өчен җыр белән бию генә бар.

– Мин – хор җитәкчесе, – диде Мирзам, тапкырлыгына куанып.

– Менә сиңа мә! Оҗмахта – хур кызлары, Сыерда – хур җитәкчесе. Гаҗәеп тә соң бу дөньялары!

Алдашу түбәнлек иде, теленнән саескан очырганда Мирзамның чәч төбенә кадәр кызарды. Тик нихәл итәсең, ялган – бердәнбер чара, аның каруы тиздән татайлар: «Без – монда хуҗа», – дип, күкрәк киереп яшәрлек үз дәүләтенә тиенәчәк иде. Халык авыз иҗатын туплаганда ул байтак хикмәти әйтемнәр отты. Татайлар: «Ялганның койрыгы кыска», – диләр, шәт, өч ай эчендә Мирзам – Илдус койрыгыннан тоттырмас, талантлы артист кебек үз ролен оста башкарыр. Нәрсәгәдер өйрәтеп артык чиләнәсе дә түгел бугай, шайтан туе уздыралар. Авыл белән авыл ярыша. Кем яхшы җырлый, кем яхшы бии – җүри бәяли, ди. Җиңүчегә афтабус бирәләр, ди. Безгә какрас кирәк, ун мәктәп баласын ташырга, әртистләрне йөртергә и тудыйм-судыймга. Әртистләр дигәч тә, шәһәрнекеләр түгел лә, үзебезнең Сыернекылар.

Мирзамның да авызы зур, аңа да сүз кыстырырга вакыт иде.

– Җиңәбез дисеңме, агай?

– Фи, тәккә генә тугыз чакрымдагы Әлпәргә әрпитисәгә ташыйммыни?! Ду куптаралар, малайгынам!

– Әлпәрдә кем өйрәтә?

– Җырчы Шакир. Радиудан ишеткәнең бардыр, «Карурман»ны шәп яңгырата. Пинсәдә хәзер, туган авылында төпләнде. Мәйтәм, Сыерда сәләмә генә җырчы кисәге дә юк бит. Клубта эшләрлек. Түләү начар шул, минем энекәшнең улы ярты ел маташты, аннары җиде меңгә ничу ыштан туздырырга дип калага тайды. Нинди җүләр тиен-миенгә яллансын ди!

Мирзам:

– Мин ялланам! – дигән иде, шофер аз гына сулы чокырга төшеп батмады.

– Кит! – Юлдашының ачудан күзе шарланды. – Түгәрәк күмәч сыярлык авызыңны җәеп миннән көлмә, яме?! Син Аргы оч Зөбәрҗәтнең шәһәрдәге стиләгә кияве бит! Шыр алдакчы! Җәлләп кенә утырттым үзеңне, җүнсез. Былтыр латарийга җиңел машина отасың дип, ике йөз тәңкәдән унбиш билет саткан идең миңа, тәгәрмәч тә тәтемәде! Әрекмән колагыңны тартып өзәм хәзер, алдакчы! – дип уң кулын рульдән ычкындырган агай куркыныч иде, егет тиз-тиз генә түш кесәсеннән таныклыгын чыгарды.

– Без Илдус исемле, агай! Сезнең авыл клубына эшкә билгеләделәр.

әгәр «әртист»ләр иренмичә, тугызар чакрымга йөри икән, димәк, дәрманлы халык. Шофер:

– Иптәш хур җитәкчесе, клуб авыл уртасында, син лутчы ары таба җәяү генә тәпилә, – дигәч, егет рәхмәтләр яудырып төшеп калды. Тәбәнәк агач клуб янында аны Айлия каршылар төсле иде. Тамаша! Иске бинаны сүтеп, аның нигезендә маңгаена «Мәдәният йорты» дип язылган яңа сарай бастырганнар иде. Мирзам ишек ягына кадакланган такталардагы исемнәрне укый-укый коридор буйлап барды. «Почта», «Китапханә», «Җирле үзидарә рәисе», «Медпункт» ише төрле оешмаларны сыендырган йортның клуб директоры Фәзилә Әүхәдиева кысрык кына бүлмәне биләгән иде. Мирзам исәнләшкәндә үк чамалады: бүлмәгә өреп тутырылган таза хатынның үзеннән битәр тавышы сыймый, тавыш диварларны дерелдәтеп коридорга ишелә иде.

– Ой, ой! Төкле аягың белән, күгәрченем! Кафил агай шылтыратты инде, сөенчегә – бүләк, ди. Шкафта өч кер сабыны бар, берсе – аңа! Культмассовикка тилмерә идек, күгәрченкәем! Культура өлкәсен җанландырыгыз, дип сүгә түрәләр, ә белгечләргә кытлык! Ничә ел ялгызым гына этләнәм, күгәрченем. Авыллар өшәнгәч кенә клуб салдыртты хөкүмәте дә.

Хатын тыр-тыр авыз пулеметыннан сиптерә генә, ә Мирзам өчен һәр минут исәптә иде.

– Сәхнәгез иркенме, Фәзилә апа?

– Әртистләребез ябык, сыярсыз. Рас син эшкә атлыгып торасың икән, иртәгә сәгать тугызда егетләр-кызлар синең карамакта булыр. Үзең белән якыннанрак танышыйк әле, күгәрченем. Кәттә киенгәнсең, ызначит башкаладан. Яшермә, нишләп ир башың белән безнең авылга ашкындың, ә? Бездә өч тиен хезмәт хакы. Хатының өйдән кудымы? Алиментттан качтыңмы? Җә, күгәрченем?

Мирзамның алдан ук һәр сорауга җавабы башындагы «компьютер»га салынган иде. Ләкин барыбер каушатты. Ялган сөйләргә күнекмәгән тел үзалдында көрмәкләнә иде. Кинәт тыштан ишекне тарттылар да, кысан бүлмәдәге тынчу һаваны соңгы тамчысына кадәр йотып бетерергә теләгәндәй, ак мыеклы бер адәм килеп тә керде.

– Аулакта гына серләшәсезме, мәхәббәт кошлары? – дип Ак мыек түргә ыргылды.

– Безнең иптәш белән важный сөйләшү, Әмирҗан абзый, – директор аны туктатмакчы иде, Ак мыек:

– Кума, яме! Минеке сезнекеннән дә важныйрак, – диде. – Без иртәгә җыелабыз, безгә залны бушат! Сәркатибем Сания өй борынча йөреп, халыкны собранҗәгә өнди.

– Хи-хи, үләм! – Юан билле Фәзилә урталай бөгелеп көлә алмады, иренен очлайтып кына хихылдады. – Бездә халык тундрадагы боз төсле, Әмирҗан абзый, собрание дип кенә кузгалыр микән! Ул лутчы телевизордан «Санта-Барбара» сериалын карап елый, синең өндәмәләреңне көтенә дә элми! Хыялланма, ыштансыз партиягез кабат терелми. Монда шәһәрдән кайтып, буржуйларны чүплеккә себереп түгәбез дип, карт-корыны котыртма, кызыл авыз! Кайсыбыз буржуй соң, кайсыбыз?

– Син! – Ак мыек күркә сыман кабарынды. – Биш сыер савасың, өч үгез асрыйсың! Син дә, иптәш культур-мультур! – Мирзам тәнкыйть утына тотылмаска тиеш, чөнки «коммунист» аның белән беренче тапкыр очраша иде. Тик ул ялгышты. – Башында буржуй кипкәсе, өстендә буржуй кәчтүме! Пастуй, пастуй! Зөбәрҗәтнең азгын кияве ләса син!

– Нинди Зөбәрҗәт кияве ди. Яңа культмассовик бу! – Фәзилә дыңгылдатып идәнгә типте. – Шудыр моннан, Әмирҗан абзый, шудыр! Тү-тү сиңа зал!

– Исем китте, клуб каршындагы мәйдан да бик шәп!

– Хи, надан, – диде хатын. – Бүген закон каты, җирле үзидарә рәисенең рөхсәтеннән башка аръяктагы тал төбендә дә җыелырга ярамый.

– Мин синең сурәтеңне «Хурлык тактасы»на элдерәм, Фәзилә! – дип янаган гайрәтле Ак мыек ишеккә юнәлгәндә, әлеге ызгыш-талаштан ун граммга ябыккан директор кәефсез генә:

– Карале, шушы «кызыл»га ияр әле, аның күршесендәге Шәкүрә әбигә фатирга урнашырсың, Илдус кем улы... Әй, исемең белән генә эндәшермен лә!

Кызылмы ул, сарымы яки яшелме, аларның уртак кушаматы «адәмнәр» иде. Йөз чөермә, һәр «төс» белән мөнәсәбәтләрне җайла, бәлки «кызыллар» арасында да яңа планетага лаек вәкилләр табылыр? Монда хисләнмичә, акыл белән уйлап сайлау кирәк иде.

Әмирҗан чалыштырып атлаган аякларына абына язып бераз теркелдәгәч, егет белән тигезләште.

– Безнең партиягә гариза язып керәсеңме, культурный иптәш?

– Сезнең илдә җәмгысы ничә фирка исәпләнә?

Дәвамы бар >

АТНА САЕН БЕР БҮЛӘК

ЯЗЫЛ!
2024 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына язып

2–12 октябрь –
ташламалы бәядән язылу көннәре

П2435 – ~~571 сум 98 тиен~~ **497 сум 34 тиен**

П2409 – ~~1255 сум 86 тиен~~ **1086 сум 18 тиен**

КВИТАНЦИЯНЕ БЕЗГӘ ҖИБӘР!

89179270040

info@vatantat.ru

420097, Казан шәһәре,
Академия урамы, 2 нче йорт

БҮЛӘК ОТ!
Атна саен бер приз иясе ачыклана.
Беренче атна бүләге –
ЭЛЕКТР ЧӘЙНЕГЕ
12 октябрьдә уйнатыла

ҖИҢҮЧЕ БУЛ!

Акциядә катнашучыларны гыйнвар аенда тагын да зуррак бүләкләр көтә

- ТУЗАН СУЫРТКЫЧ
- КЫСКА ДУЛКЫНЛЫ МИЧ
- ИТТАРТКЫЧ
- МУЛЬТИПЕКАРЬ
- ҮТҮК

Тулырак сайтта: vatantat.ru
Акция 2023 елның 29 сентябреннән башлап 2024 елның 10 февраленә кадәр дәвам итәчәк.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама +16



БУЛМАС ДИМӘ, ТОРНА БУ!

Даурия торнасы – сирәк кош. Америкада төшерелгән бу фотода – Чикләвек (Walnut) кушаматлы торна һәм зоопарк караучысы Крис Кроу. Эш шунда ки, Чикләвек Криска гашыйк булган һәм ул аны үзенең пары дип кабул итә. Әлеге торнага ике тапкыр ата кошлар биреп караганнар, икесе дә үле килеш табылган. Бу – бик сирәк токым, шуңа күрә аны үрчетү өчен зоопарк хезмәткәрләре бөтен көчләрен куялар. Крис ярдәмендә Чикләвекне ясалма рәвештә «авырга уздырганнар». Соңрак ир-ат торна белән бергә күкәйләр өстендә утырырга мәҗбүр була. Чикләвеккә бу бик ошый. Криска «сөйгәне»нә якынрак булыр өчен махсус

бию дә башкарырга туры килә. Хәзер Чикләвеккә – 41 яшь, ә Криска – 47. Билгеле булганча, бу төр торналар 60 яшькә кадәр һәм аннан да күбрәк яшәргә мөмкиннәр. Биологлар фикеренчә, әгәр бу парны аерсаң, торна ялгызлыктан үләргә дә мөмкин. Димәк, Крис Кроуга якын арада пенсия күрәсе юк икән әле…

Беләсең килсә...

1 **Тырнак авырулары буенча табиб ул:**
а) подолог;
б) трихолог;
в) сомнолог.

2 **Бу исем «җиңү» дигәнне аңлата:**
а) Олимпиада;
б) Виктория;
в) Капитолина.

3 **«Бүре каны» повестен кем язган?**
а) Мәдинә Маликова;
б) Зифа Кадыйрова;
в) Нәбирә Гыйматдинова.

4 **1941 елның 22 июнендә Бөек Ватан сугышы башлану турында хәбәрне радиодан беренче булып кем җиткерә?**
а) Сталин;
б) Молотов;
в) Жданов.

Җаваплар: 1. а); 2. б); 3. в); 4. б).

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Картуф, Мишә, хәдис, комган, мә, Акбай, җә, Лев, иму, ел, гарык, Канада, әле, чык, Гуниб, Урам, мәче, кала, Али, үч, елама, як, Ра, юк, НТВ, ТНВ, би, Әлфинә, әр, казу, елак, Имәни.

Вертикаль: Кәкерле, чикерткә, елкы, Алан, ре, Рәмиев, акула, Рамю, яка, уха, чага, акт, ак, Фән, Дума, әз, аҗаган, Луи, мичкә, ими, ис, ирәбә, Янбикә, маймыл, чуктин, әсәй, үкенеч, әзи.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14047 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 334

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+